
РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН



رحلة المرجانى

Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре



رحلة المرجاني

Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре

Казан, 2018 ел

УДК 28

ББК 86.38

Р. Фәхретдин

Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре – Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2018. – 64 б.

Шиһабетдин Мәрҗанинең 1297 елда Гарәбстанга сәфәре вакытында янында булган хәтер дәфтәреннән җыеп алынган мәгълүматлар. Олы галимебезгә хезмәт булсын һәм дусларга ядкәр калсын диеп вакыт сарыф итеп тырыштык. Кайбер нәрсәләрнең аңлатмасын астөшермәләрдә китердек.

Мулла Ризаэтдин бине Фәхретдин

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте голәмәләр шурасының 18-17 нче номерлы бәяләмә белән басарга хупланган.

Хәзерге татар әдәби теленә күчерүче – А. И. Кадыйров.

6+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ.

«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан, Лобачевский урамы, 6/27
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42.
Сайт: http://www.huzur.ru
Электрон почта: marketing@huzur.ru

Оригинал-макеттан басарга кул куелды: 05.12.2018
Форматы 60×84 $^1/_{16}$, басма кәгазь: 4;
офсет кәгазендә бастырыла
Тиражы 1000 данә.
«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.
Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.

ISBN 978-5-6041838-0-9

بسم الله الرحمن الرحيم

Һижри 1297 елның Рамазан аеның 17 нче көнендә (милади 1880 елның 11 нче августында), иртәнге намаздан соң, Мәккәгә юл алып, Казаннан аерылдык. Пароход белән Нижнийга килдек. Аннары тимер юлы белән Мәскәү, Курск һәм Киев шәһәрләрен узып, Одессага килеп җиттек. Бу арада дикъкать итәрлек бер хәл булмады. Казан белән Одесса арасы 2385 чакрым чамасы булыр.

25 нче Рамазан – Одессадан Истанбулга юнәлдек.

27 нче Рамазан – пәнҗешәмбе көнне Истанбулга килеп җиттек. Янымда булган мөсхәф шәрифләрдән башка, «Нәзарат Әл-Хакк», «Хакк Әл-Мәгърифә», «Фәваид», «Мөнтәхаб Әл-Вәфия», «Мохтасар Әл-Вәкая», «Бәбурия»[1], «Сәбат Әл-Гаҗизин»[2],

[1] «Бәбурия» китабының авторы – Заһиретдин бине Мөхәммәд бине Мирза шәех. 888 елда туып, 899 елда Фирганәнең падишаһы булды. 932 елда Һиндстанда яу белән Дәһлине яулады. 38 ел патшалык иткәннән соң, 937 елда 49 яшендә вафат булды. Галим һәм өстен әхлаклы кеше булып, телгә алынган «Бәбурия» китабында ул үзенең тормыш-әхвәлләре турында яза.

[2] Бу китап төрки телендә булып, авторы Әбү Мөхәммәд Аллаяр бине Аллаколы исемле кеше. Халкыбыз арасында мәшһүр булган бу китап Казанда күп тапкыр басылды. Авторы 1130 елында вафат була.

«Мәҗмаг Әл-Әдәб»[3], «Фазаил Әш-Шөһүр»[4], «Тарих Әбү Әл-Гази»[5] нөсхәләрен дә үзем белән алган идем.

Истанбул[6]

28 нче Рамазан – Солтан Сөләйман мәчетендә җомга намазын укыдык, икенче көнне Айя София мәчетендә өйлә намазын укыдык.

30 нчы Рамазан – Әбү Әюб Әл-Әнсари мәчетендә булдык, мәчетнең югары катындагы Хырка-и Сәгадәтне менеп карадык. Риваятьләрдә әйтелгәнчә, бу хырка – Расүли Әкрамнең (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Үвәйс Әл-Карани[7]

---

[3] «Мәҗмәг Әл-Әдәб» китабының авторы – Сәет авылының имамы – Һибәтулла Сәет Баттал исемле кеше. 1282 елда вафат булып, Сәет зиратында күмелгәнлеге билгеле.

[4] Бу китапны Габделҗаббар бине Габделкәрим Әл-Алматыйга нисбәт иткән булсалар да, китап Болгар галимнәре әсәрләреннән булса кирәк, дөресен Аллаһы белер.

[5] Әбү Әл-Газыйның исеме Мөхәммәд бине Гарәпхан булып, үзе мәшһүр Чыңгыз нәселеннән булуы сөйләнелә. 1074 елда 60 яшендә вафат була. Татарлар хакында бәян иткән шушы тарих китабы, 1287 елда барон Демизон исемле кешенең тырышлыклары белән Санкт-Петербургта бастырылып, Европа телләренә тәрҗемә ителде.

[6] Мөхтәрәм Мәрҗанинең килүе турында белеп алган Истанбул газеталары моның турында шулай дип язды: «Казан галимнәреннән мөфти Шиһабетдин ахунд әфәнде хәзрәтләре, ярлыкау эзләп Хиҗазга таба юл тотмакта. Бу юлы Истанбулга килеп, ул Бохара дәрвишләренең мондагы башлыгы – шәех Сөләйман әфәнде ярдәмчелеге белән олы һәм билгеле шәхесләрнең кайберләре белән очрашты. Исеме телгә алынгын әфәнде үзе дә билгеле һәм мөхтәрәм бер зат булып, сарф вә нәһү, мантыйк, фәлсәфә, тәфсир, фикһ, әхлак һәм тарих буенча 30га якын гарәпчә китап һәм аңлатма авторы. Истанбулда күрешкән олы шәхесләргә ул үзенең китапларын бүләк иткәне сөйләнелә".

[7] Һиҗри 37 елда дин өчен сугышып үлгән Ибне Гамир булса кирәк.

хәзрәтләренә биргән бер бүләге иде. Айя Софияда Хырка-и Сәгадәттән кала әле мөкатдәс байрак, мөкатдәс аяк киеме һәм хәзрәти Госман Коръәне дә саклана. Солтан Мөхәммәд Әл-Фатих бине Морат (рахимәһуллаһи) каберен күреп, мәчетнең эченә дә кереп карадык, соңыннан Мөхәммәд Рәхим әфәндегә барып, ифтар кылдык.

1 нче шәүвәл – дүшәмбе көнне иртәнге намаздан соң каек белән Долмабахче тарафына чыгып, гает намазын укыдык. Бу көннәрне Зыяэтдин бине Габдеррафигъ Әл-Мөнкәри һәм Исхакка кунакка чакырылган идек. Нур Госмани мәчетен күрергә бардык.

3 нче шәүвәл – Вафа мәчетендә икенде намазын укып, киченшәех Сөләйман әфәндегә[8] кунакка барып, сөйләшеп утырдык һәм икенче көнгә кадәр өендә калдык.

5 нче шәүвәл – Солтан Сәлим мәчетендә җомга намазын укыдык. Солтан Сәлим I мәчетенә барып, Солтан Сәлим вә Габделмәҗид каберләрен күрдек. Сәет Мостафа бине Нәҗиб исемле берәүнең каләме белән Солтан Сәлим мәчетенең гомбәзенә язылган тугыз юллык шигырьне күчереп язып алдым. Мәчеттә берникадәр «Ән-Нисә» сүрәсен укыдым. Җомга намазыннан соң хатыйб Хафиз Исмәгыйль әфәнде белән бергә каек белән бронялы «Мәсгудия» көймәсен карарга бардык. Мең башы Гариф бәк әфәнде көймәне безгә күрсәтеп, бәйнә-бәйнә аңлатты. Аннары каһвә китереп, безне сыйла-

---

8 Шәех Сөләйман Кодратуллаһ Әл-Кундузи. Каракүлдә туып, чыгышы белән Кундуз якларыннан. Анасы ягыннан Гобәйдулла ишан Каракүлле һәм Яхъя ишан Төрекмәни белән туганлыгы бар. Нәкшебәнд «тәхәллүсе» бар. Хәзер Истанбулда яши. 1298 елда Истанбулның «Мехран» матбугат йортында бик тә файдалы «Чагатай һәм Госманлы төрекләре телләре» исемле әсәре басылып чыккан иде.

ды. Шул бронялы «Мәсгудия» Англиядә ясалган, биш йөз мең лира кыйммәтендә икән. Корал һәм җиһаз бәясе әле моңа керми икән. Фән белән таныш булмаган кешегә боларны аңлату мөмкин түгелдер. Гариф бәк безне бик җылы кабул итеп, танышканыбызга сөенечен белдерде. Исемнәребезне сорап алды. Калган каекларыбызны кайтарып куерга боерып, безне искиткеч каекларга утыртып җибәрде. Гаскәриләре безне олылап озатып куйды.

Шул ук көнне шәех Мөхәммәд әфәнде Әл-Эдирнәви янына барып, үзе белән очраштык. Ак чәчле кемсә булып чыкты. «Үзегез килеп мине бик олыладыгыз, мин сезгә барырга тора идем», – диде. Бу кемсә – Шәех Әл-Ислам Хәсән бине Госман Фәһминең[9] шәкерте икән.

6 нчы шәүвәл – Шәех Әл-Ислам Әхмәт Әсгат әфәнде янында булдык. Бик хуш сөйләшеп утырдык. Соңыннан баш казый Җәүдәт Паша[10] хәзрәтләре белән күрештек. Рәхим итеп каршы алды. Бешикташ вә Бейоглу якларына барып, нәкыйб әл-әшраф сәет Сәлман Әл-Багдади[11] белән күрештем. Яшь,

---

[9] Әбү Хәйдар Хәсән бине Госман бине Хәсән (рахимәһуллаһи). Төркиянең олы галимнәреннән булып, ике тапкыр Шәех Әл-Ислам мәртәбәсенә ирешкән зат. Мөхәммәд бине Галәветдин бине Габидин (рахимәһуллаһи) бу затны үзенең «قُرَّةُ عُيُونِ الأَخْيَارِ» исемле китабында телгә ала. Хөрмәтле Мәрҗани турында камил, яхшы фикерле булганлыгы турында риваять итә. 1298 елда 80 яшендә Мәдинәдә вафат була.

[10] Әхмәт Җәүдәт Паша бине Исмәгыйль бине Гали бине Әхмәт бине Исмәгыйль бине Әхмәт. 1312 елның зөлхиҗҗә аенда вафат була. Мәшһүр язучы һәм галим кеше иде.

[11] Бу кеше Мөхәммәд Бәйрәм бине Мостафа бине Мөхәммәднең беренче шәехе булган зат. Исеме «صَفْوَةُ الإِعْتِبَارِ» исемле китапның 5 нче томының 10 нчы фасылында телгә алынып, китап азагына 1299 елның 19 нчы җөмәдәл-әүвәл тарихында язылган бер хаты да кертелгән.

күркәм йөзле, төзек гәүдәле, гаять әдәпле һәм укымышлы кеше булып чыкты. Гарәпчә, төрекчә һәм фарсы телләрендә яхшы сөйләшкәнлеге аңлашылды. Янында булган Дәрвиш бине Ибраһим Әл-Көрди Әл-Багдади дигән кеше белән дә таныштык. Шуннан – сәет Фазыл Әл-Галәви бине Мөхәммәд бине Сөһәйл Әл-Хадрами Әш-Шәфигый өенә бардым. Үзе солтан янында булганга, безне улы кабул итте. Бу мәҗлестә сәет Габделкадир Әл-Җәзаиринең улы да бар иде. Беркадәр вакыт үткәч шәех сәет Фазыл хәзрәтләре үзләре дә кайтып керде. Күңелгә хуш мәҗлес һәм әңгәмә узды. Шәүкәни[12] белән Бхопалы[13] турында сүз кузгалгач, сәет Фазыл хәзрәтләре аларны ваһһабиләр диеп атаса да, улы – Шәүкәнинең гыйлеме камил булганлыгын раслады. Шушы кунакта булган мөхтәрәм затларга үз китапларыбыздан бүләк бирдек. Бу көннәрне Мирза Салих әфәндедә дә кунакта булдык.

9 нчы шәүвәл – тышкы эшләр министры Касым Паша һәм Мәккә олыларыннан берсе булган – сәет Гәвен бине Мөхәммәд бине Гәвен (шәех Хөсәен абыйсы була) белән күрештек. Шәриф җәнаплары төрекчә белсә дә, минем белән гарәпчә аңлашты. Файдалы сөйләшү һәм ләззәтле әңгәмә булды. Гаять галим һәм затлы кеше икән. Тарих, география һәм астрономиядән күп нәрсә белгәнлегенә гаҗәпләндем. «Нәзарат Әл-Хакк»

---

12 Мөхәммәд Гали бине Мөхәммәд Әш-Шәукәни (рахимәһуллаһ). Гаять галим һәм мөхтәрәм, гыйлемдә үз замандашларыннан күпкә алга киткән бер кеше иде. Йәмән казыйларының казые һәм чиксез күп китап авторы иде. «Фәтх Әл-Кадир» исемле дүрт томлы тәфсир авторы булганлыгы билгеле. Шәкертләре аның турында «мөҗтәһид әл-мотлак» дип әйтәләр иде. 1255 елда вафат була.

13 Әбү Әт-Тайийб Сыддыйк бине Хәсән Әл-Хөсәйни (рахимәһуллаһ). Бхопалда хөкем иткән, күп китап язып калдырган бер зат. Дүрт томлы «Фәтх Әл-Бәян» тәфсире – аның бер әсәре. 1359 елда вафат була.

исемле китабыбыз турында ишетеп, китапны укырга теләге турында сөйләде. Илебездә көн һәм төн озынлыклары турында, кояшның чыгуы һәм батуы турында сорашты, илебезнең шәкертләре, галимнәре һәм, гомумән, мөселманнары турында күп сорашты. Халкыбыз арасында Европа мәгърифәтенең таралганлыгы турында сорады. Мин халкыбызның гыйлемлелек дәрәҗәсе турында, халыкны укыту рәвешләре турында мәгълүмат бирдем. Һөнәр гыйлемнәре бездә аз дип, булганнары – кагыйдәсез һәм гамәли тәҗрибәсез укытылганлыгы турында хәсрәтләнеп сөйләдем. Яңа астрономик ачышлар турында мәкаләм барлыгы турында сөйләдем. Моңа җавап итеп: «Казанга кайткач, ул мәкаләгез белән «Нәзарат Әл-Хаккны» миңа җибәрегез», – дип сорады. Аннары: «Менә сез үзегез төрки, халкыгыз да төрки», – диде – «алар өчен язылган китапларның да төрки телендә булуы кирәк иде, әмма ни өчен сез әсәрләрегезне гарәп телендә язасыз?» – диеп сорады. «Гарәп телен безнең галимнәребез дә, шәкертләребез дә белә. Бүтән илләрдә укырга теләүче дә табылыр дип, гарәп телендә язабыз», – дип җавап кайтардым. Бу сүзем белән килешеп: «Шулай, гарәп теле – уртак тел», – диде. Мин китәргә рөхсәт сорагач: «Сөйләшеп туймадым, кайтканда яңадан килегез», – диде. Мин: «Гасыр Сәгадәттән без инде ерак калган булсак та, әлхәмдүлилләһи, Пәйгамбәр нәселенең бер вәкиле белән күрешеп, бер мәҗлестә утыруы безгә дә насыйп булды!» – дигәч, бигрәк тә канәгать калды. Янынннан чыккан вакытта, урыныннан торып, мине беркадәр вакыт озата барды. Кулын алып үптем һәм тәэсирләнгән хәлемдә хушлаштым. Бу көннәрдә мәгариф министры Мөниф Паша урыныннан алын-

ган иде. 7 нче шәүвәл көнне Садр-и Әгъзәм Кадри Паша урыныннан алынып, урынына Сәет Паша билгеләнгән иде.

10 нчы шәүвәл – пароход белән Истанбулдан аерылып, Искәндәриягә юл алдык. Галлиполы белән Чанаккаледан узып, Измирда туктадык. Туктаган вакытта без иртәнге намазны укып тәмамлаган гына идек. Шул вакытны бер иранлы килеп, миннән кыйбла сорады. Мин күрсәткән тарафка карап ике рәкәгать намаз укыды. Кыямда кулларны кендек астына куеп, икенче рәкәгатьтә «Фәтихә» сүрәсенә «Ихлас» сүрәсен кушты да, рөкүгъ алдыннан «Конут» догасын укыды. Утырганда тәшәһһүдне Ибне Мәсгүд (радыяллаһу ганһе) укыган кебек укыды, ләкин беренче тәшәһһүдтә «вәхдәһү» сүзен арттырып сөйләде.

Измир

12 нче шәүвәл – Измир шәһәрен карарга чыктык. Шәһәрнең яр буе бик матур, шома таш җәелгән. Матур мосафирханәләре бар. Бер атлы трамвай йөри. Моннан тыш әле тимер юллары һәм матур кибетләре бар. Ишәк, качыр һәм дөяләрен арбага җигеп, йөк йөкләп, төрле нәрсә ташыйлар. Фаэтон белән каретalar да бар диделәр. Бик зиннәтле сәүдәханәләре, машиналы фабрика һәм заводлары бар. Йөзем, инҗир, әфлисун һәм башка нәрсәләре бик югары сыйфатлы һәм күп. Итнең яхшысы күп. Мәчет һәм чиркәүләре күп һәм матур. Киң урамнары бар, күпчелеге тар, ләкин барысы да таш белән түшәлгән. Каек белән йөреп килү бик арзан. Юлда очраган Сәйфулла бине Гали исемле кеше безгә юл күрсәтеп бераз йөртеп килде. Безне юлыбызда очраган ак чәчле бер кеше белән күрештереп:

«Сезнең якташыгыз», – диде. Бу карт тыныч кына утырып тора иде. Хәл сорашканнан соң, бу кешенең Кошман имамы Шәрәфетдин бине Фәхретдиннең абыйсы – Шәмсетдин хаҗи икәнлеге билгеле булды. 1248 елда Бохарага китеп, биш ел анда торганнан соң, бу шәһәргә килгән икән. Балалары һәм оныклары да бар. Безгә дөньясы иркен, яшәү шартлары яхшы икәнлеге турында сөйләде. Аннары Борай янындагы Тугай авылыннан Хөснияр бине Шахимәрдән исемле кеше килеп, безнең белән күреште. Безгә юл күрсәтеп баручы Сәйфулла әфәнде Констанцадан күчеп килгәнлеге турында, «Башта бай идем, хәзер инде фәкыйрьләндем», – диеп сөйләнде. Җомга намазын уку өчен мәчеткә кердек. Тәхият әл-мәсҗед намазын укып, бер җүз Коръән укыдым. Мин укыган Коръән нөсхәсе гаять матур язу ысулы белән язылган иде. Аятьләр бит ахырларына таба тәмамланып килә иде, ләкин буяулары бик сулган, тукталыш урыннары да һичберничек билгеләнмәгән иде. «Һуд» сүрәсендә {ولاَ تَمَسُّوهَا بِسُوءٍ} аятендә «لاَ» сүзе төшеп калдырылган иде, һәм {ولاَ تَرْكَنُوا إِلَى ٱلَّذِينَ ظَلَمُوا} аяте кәримәсендә «ٱلَّذِينَ» сүзе урынына мөкатдәс «الله» сүзе язылган иде. Бу ике ялгышны мин төзәттем. Бу вакытта соңгы рәттәге берәү кычкырып «Кәһаф» сүрәсен укый иде. Гәрчә тукталыш урыннарына игътибар бирмичә, сузып укыла торган авазларны артык сузып укыса да, бүтән яклардан укуы күңелгә бик тә хуш иде. Манара азаны әйтелгәндә, үз сәгатьләренә күрә һәм безнең сәгатьләребезгә күрә дә алтыга әле ун минут вакыт бар иде. Әмма минбәр азаны әйтелгәндә сәгатьләре алты тапкыр сукты. Минбәрләренең ундүрт баскычы бар иде. Хатыйб кулына берни тотмыйча, минбәрнең яртысына менеп, ике кулын ике як токага куеп укыды. Фарыз намазында «Кәүсәр» сүрәсе

белән «Ихлас» сүрәләрен кушып укыды. Ихтияте зухр намазын укып тормады. Аллаһны мактау һәм олылау сүзләрен кабатлап әйтмәсә дә, «نَشْهَدُ» диюе белән дини мирасына бераз каршы төште. Измир мәчетләренең кыйбласы безнеке белән чагыштырганда 45 градуска сулдарак. Мондагы мәчетләрнең михраблары өстендә {فَلَنُوَلِّيَنَّكَ قِبْلَةً تَرْضَيهَا فَوَلِّ وَجْهَكَ شَطْرَ ٱلْمَسْجِدِ ٱلْحَرَامِ} аяте, диварларында {إِنَّ ٱلصَّلَوٰةَ كَانَتْ عَلَى ٱلْمُؤْمِنِينَ كِتَٰبًا مَّوْقُوتًا} аяте язылган. Азан алдыннан мөәзиннәр салават әйтәләр, әмма Истанбулда фарыз намазы алдыннан өч тапкыр «Ихлас» сүрәсен укыйлар. Җомга намазыннан соң Коръән укылмый.

12 нче шәүвәл – кояш баеган вакытта Измирдан киттек. Аннан Сагыз утравына, аннан – Грекларның яхшы корылган шәһәрләренең берсе – Ширә шәһәренә бардык.

Истанбулдан булган бер егет белән танышып, саф гарәпчә бүгенә сөйләшеп бардык. Әхлаклы, акыллы һәм зирәк кеше булып чыкты. Мисырда дәүләт хезмәтендә хезмәт итәмен диде.

Искәндәрия[14]

17 нче шәүвәл – пароходтан төшеп, Кулдаш бай бине Камалетдин Әл-Бохаридә урнаштык. Шәһәрдә мәчет күп булуы билгеле, шуларның иң мәшһүре – имам Бусайри мәчете. Бу мәчет бик матур һәм соклandыргыч олы, гөмбәзе алты чуен багана өстенә корылып, эче яхшы паласлар белән түшәлгән. Шәһәр урамнарының күбесе туры һәм тигез булып, таштан салынган. Яхшы фаэтон һәм арбалар йөри. Халкы бик күп, сөйләшүләре гарәпчә.

[14] Бу шәһәрнең коручысы – Искәндәр Әр-Руми, ягъни Искәндәр Македонский. Һиҗрәттән 935 ел элек яшәгән мәшһүр бер падишаһ иде.

Ахшам намазын укыр өчен кергән мәчетебездә, шәфигыйләр фарыз намазы алдыннан икешәр рәкәгать нәфел намазы укыганнырын күрдек. Фарыз намазы тәмамлангач, һәркем сөннәт намазын аерым укып чыгып китте. Имам белән бергә дога кылу булмады. Бу шәһәрдә Даниил (галәйһиссәлам), Локман Әл-Хәким, Искәндәр һәм Сәгъд бине Әбү Әл-Ваккас (радыяллаһу ганһүм) каберләре булганга күрә, гади халык шуларны күрү өчен монда килә.

19 нчы шәүвәл – Әбү Әл-Габбәс мәчетендә җомга намазын укыдык. Хатыйб бер кулы белән хәнҗәргә тотынган хәлдә, Аллаһыны мактау һәм олылау сүзләрен бер генә тапкыр кабатлап, шәһәдәтне «أَشْهَدُ» – дип, так санда әйтте. Хөтбәсе матур иде. Фарыз намазын тәмамлап, сәлам биргәч, бер яннан торып китте.

20 нче шәүвәл – тимер юлы белән Каһирәгә киттек. Урыныбыз – икенче класс урыны иде. Тимер күпердән Нил елгасы аша үттек. Берәр урынга җиткәндә: «Шушындый тукталышка җитәбез», – диеп кычкырып баралар иде. Мәскәү белән Одесса арасында телеграф баганаларына куелган саннарны укып, санап бардым. Бу юлы алай санап барып булмады, баганалар күзгә чагылып кына кала иде. Поездның бик кызу һәм тиз баруына гаҗәпләндек.

Каһирә

20 нче шәүвәл – Каһирәгә барып җитеп, хаҗи Камалетдин бүлмәсендә урнаштык. Бүлмәсе биектә иде, кырык сигез баскыч санадым. Каһирәдә олы биналар күп, боларның берсе – Мөхәммәд Гали Паша мәчете. Бу мәчет Истанбулның

олы мәчетләре кебек үк зур булмаса да, корылышын, кыйммәтлелеген һәм зиннәтлелеген аңлатып бетерерлек түгел. Эче һәм тышы мәрмәр ташыннан эшләнгән. Ахак ташы кебек кып-кызыл төстә, гөмбәзе алтын белән капланган. Диварларында гарәпчә һәм фарсыча язулар һәм шигырьләр, кайберләрен үзебезгә язып та алдык[15]. Мәчет янындагы күшәкне дә кереп карадык. Хаммамы, бәдрәфе һәм бакчасы бар икән. Бик күп бүлмәләре бар, һәрберендә кыйммәтле паласлар җәелгән. Андагы өстәл, диван, караватһәм көзгеләрнең матурлыгын һич аңлатырлык түгел. Мөхәммәд Гали Паша кабере дә шунда: янына барып дога кылдык. Мәчет ягыннан карaганда, Каһирә шәһәре бөтенләе белән күренә, Нил елгасы җәелеп ята. Аннан Әс-Сария мәчетенә киттек, шуннан соң олы шәхесләр күмелгән Садәт Бәкрия зиратына бардык. Анда шәех Әш-Шәтыбый хәзрәтенең кабере янында дога кылдык. Моннан кала билгеле галимнәр һәм мәшһүр ирләрнең, хосусан, сәетләрнең һәм шәрифзадәләрнең каберләре янына бардык. Шуннан соң төрле мәчетләрне карап, йөреп чыктык.

22 нче шәүвәл – шимбә көнне «Мәхмәл-и Шәрифне»[16] унҗиде дөягә төяп, туп атып, музыка уйнап, барабаннар кагып,

---

15 Күчереп алынган шигырь шушы:

و هل ياصاح يعرب عن علي   مؤثرة دون البناء المشيد
فدع قصر عمان أو أهرام حرمس   وإيوان كسرى إن أردت تهتدي
و دع إرما ذات العماد و نحوها   و عرش لبلقيس كصرخ ممرد
و دع أموال و أنزل بمصرنا   و بادر إلى هذا بايماء مرشد

16 Мисыр һәм Каһирә турында язылган китаплардан аңлашылганча, Мәхмәл-и Шәриф – Мәккәдәге Кәгъбәне ябу өчен тегелгән яңа япманы юлга озату тантанасы ул. Шушы япманы юлга озату көне Мисыр кешеләре өчен бәйрәм була торган булган.

гаять тантаналы рәвештә Мисырдан озатканнырын күрдек. Шуннан соң, бер алтын француз акчасына фаэтон яллап пирамидалар[17] карарга киттек. Пирамидалар күп җирдә табылган булса да, өч иң олысы бер урында урнашкан. Без иң олысының эченә кереп карадык. Түбе киң, очы – тар булып, ерактан арыш кибәне кебек күренсә дә, үзе бик биектер. Тыштан, өч ягында да, җәяү менеп эченә керү өчен унбиш аршинлы баскычлар ясалган. Эчкә кергәннән соң, башта түбән төшеп, аннары туры барганнан соң бер бүлмәгә килеп чыгасын. Шушы бүлмәдән тышка чыга торган ике юл бар. Пирамида эчен карап йөреп бетергәннән соң, хөрмә белән тары икмәге сатып алып ашадым, Нил буенда утырып су эчтем. Шәһәр белән пирамидалар арасы – сәгать ярымлык юл – 13 чакрым тирәсе. Юл күрсәтеп баручыларына ике тәнкә акча бирдек.

Юллары дамба кебек күтәртелеп ясалган иде, өч аршин саен агач утыртылган иде. Юл буенда матур бакчалы, таш койма һәм тимер рәшәткә ихаталы, тимер капкалы гаскәр тораклары күренә иде. Шунда өч катлы бер бинаның бер катында өч йөз тәрәзә санадым. Бу сәфәребездә Мәхмүд бәк Әл-Фәләкидә кунакта булдык. Үзе галим һәм гади кеше, мәҗлесе күңелгә хуш булды. Юлыбызда Ибраһим Паша һәйкәлен күрдек. Биек таш өстенә чуен атка мендереп, чуеннан коеп куелган. Сакалы агарган, башына фәс кигән. Бер кулын сузып, нәрсәгәдер күрсәтеп торган кебек.

23 нче шәүвәл – тимер юлы белән Суэцка киттек. Әз-Зәказыйк исемле урында вагоныбызны алмаштырдылар.

---

17 Фиргәвеннәрнең тәннәрен кумеп кую өчен махсус төзелгән олы корылмалар. Мисырда мондый каберлекләрнең саны 39 артык булганлыгы турында сөйләнелә.

Каһирәдән чыккан поездның номеры 1047 иде, ахырдан 177 булды. Русия поездларында вагоннар 88 кешелек, мондагылар, мичләре булмау сәбәпле, 96 кешелек иде. Искәндәрия–Каһирә–Суэц тимер юлы өстендә заводлар күренеп калды. Каһирәдән киткән көнне үк Суэцка килеп җиттек.

Суэц

Суэцта хаҗи Гали Әл-Хәнәвәкәндидә туктадык. Монда өч кич кундык. 18 нче сентябрь көнне ахшам намазыннан соң диңгезгә кереп госел коендык. Бу шәһәрдә кобтый һәм христианнар өчен махсус өч гыйбадәт кылу урыны, мөселманнар өчен биш мәчет бар. Унөч кадәм биеклегендәге ике баскычтан менеп, бер мәчеткә кереп намаз укыдык. Ахшам вакытында шәм якмыйлар икән.

26 нчы шәүвәл – пароходка утырып юлга чыктык. Икенче көн иртәнге намаздан соң, өстемдә ялгыз бер кат җәйге күлмәк белән генә, палубада «Йосыф» сүрәсен укып бардым.

Янбугъ

29 нчы шәүвәл – иртә белән Янбугъ исемле шәһәрдә төшеп, Әхмәт бине Гали исемле кешедә урнаштык. Ике мәҗидиягә куй сатып алдык. Гарәпләр: «Бәлх!» – диеп хөрмә, «Хубз!» – диеп икмәк, «Фатыйр!» – диеп төче коймак, «Сәмәк!» – диеп кызыл, зәңгәр, яшел һәм чуар төсле балык китереп сатып йөри. Гарәп хатыннары күзләрен һәм борыннарын ачык калдырып, йөзләренә өч почмаклы кара нәрсә каплап киеп йөри. Шул нәрсәгә дүрт алтын яки алтынланган көмеш тезгән бу-

лыр. Әле моңа өстәп, маңгайларыннан борын очларына кадәр, безнең уникеле үлчәүнең бәләкәй герләренә охшаган, берсе икенчесеннән кечкенә нәрсәләр тезеп төшкән булыр. Муеннарына өч яки дүрт кат мәрҗән һәм сәдәфкә охшаган нәрсә асканнар, башларына бөркәнгәннәр. Бу бөркәнчек күбрәк кара төстә булып, аякларына кадәр каплар. Әмма хезмәтчеләренең йөзләре һәм күкрәкләре ачык, аяклары ялангач булыр. Кайберләре кичләрен шигырь дә сөйли. Янбугъ хатыннары һәм хәтта кызлары да, урамга чыкмый, кешегә күренми һәм тавышларын ишеттермиләр икән.

Янбугъ яр буе таш тезеп читләнгән. Диңгез буенда ничә урында бодай өеп куелган. Кәҗә ашамасын диеп, гарәпләр бодай өстенә менеп утырганнар. Янбугъта чебеннәр бик күп, ләкин ачы тешләмиләр. Бүлмәбезгә берәү кереп чәй эчеп чыкты, моны күреп алган Мисырдан килгән черкас шәкертләре: «Мә шә Аллаһ, Ибраһим Паша ич бу!» – диеп гаҗәпләнделәр. Шәүвәл ае тәмамланып, зөлкагъдә аеның яңа ае күренүе Янбугъта чәршәмбе көнне булды.

2 нче зөлкагъдә – Фәйзулла һәм Зәйнулла белән зиратка барып, таштагы язуларга карап, хаҗи Хөсәен бине Йосыф[18] каберен эзләп йөрдек. Таштагы язулардан таба алмагач, бер кабергә «шушы булса кирәк» дип, Коръән укып багышладык. Аллаһы Тәгалә кабул итеп, рухын шатландырсын.

---

18 Бу кемсә – Казанның иске карашлы кешеләреннән булмады. Яңа төркичелекне алга сөреп, үзе кәсеп иткән малын варисларына байлык итеп калдырган һәм хәйрия эшләренә кызганмый сарыф иткән кеше иде. 1281 елда хаҗдан кайтканда вафат булды. Милләтне онытмаган байларны милләт тә онытмас. Шуның өчен мөхтәрәм Мәрҗани хәзрәтләре аның каберен эзләгән дә күрәсең. Бездән соң да онытмасыннар дип, без монда язып калдырабыз.

3 нче зөлкагъдә – җомга намазын укыдык. Хатыйб Аллаһны мактау һәм олылау сүзләрен бер генә тапкыр әйтеп, шәһадәтне «أَشْهَدُ» дип, так санда әйтте. Хәлифәләрне (радыяллаһу ганһум) икенче хөтбәсендә искә алды. Хөтбәне яхшы һәм матур сөйләде.

4 нче зөлкагъдә – Рашид һәм Гаэт исемле кемсәләрнең дөяләрен яллап Мәдинәгә киттек. Дөя бер сәгатьтә мең өч йөз алтмыш адым атлый диләр. Әмма Сүрия кәрваны белән барганда, мин дөяләрнең мең өч йөз генә адым атлаганнарын санадым. Сахрада зур ябалдашлы агач күреп, бер гарәптән агачның исемен сорадым. «Шир», – диде, аннары яңадан: «Тальх», – диде. Биъре Сәгит дигән урынга җиткәч авырып киттем.

7 нче зөлкагъдә – Җәдидәгә җиттек. Монда биек тау башыннан чишмә булып агып чыккан бер су күрдек. Суы эссе һәм куәтле булып ага. Вакытында бу чишмәнең караучысы Зөбәйдә[19] иде, дип сөйлиләр.

Иртәнге намазны укып, бераз йоклап уянганда, тирләгән идем. Шунда яныма Ишмөхәммәд хаҗи исемле бер казах килеп, авырткан кулымны акрын гына бик озаклап уды. Шуннан соң кулым бераз рәхәтләнде. Аннары Мәдинәдән хаҗи Шәгъбан бине Гобәед исемле бер кеше лимон китереп, ак җеп сорап алып, аны берничә кат итеп җиде урыннан төенләп, өшкереп, уң кулыма бәйләп куйды. Иптәшләребез бу кешене Янбугъта Ибраһим Паша белән бергә кергән кеше иде диделәр,

---

[19] Бу Зөбәйдә – Һарун Әр-Рашид хәлифәнең хатыны. Матурлыкта һәм күркәм сүзлелектә тиңе юк иде. Тәкъвалык һәм юмартлыкта да беренче иде. Хиҗаздагы Зөбәйдә чишмәсенең караучысы да, Тәбриз шәһәренең коручысы да ул иде. Һиҗри 116 елда вафат итте.

ләкин ул минем хәтеремдә нигәдер калмады. Бу кемсәнең безгә күп файдасы булды. Аеруча дөячеләрне: «Болар – яхшы кешеләр, аларга хезмәт итегез, рәнҗетмәгез», – диеп кисәтеп һәм искәртеп куйды. Ул көнне һава да мөлаем булды. Хәлем дә җиңеләйгән кебек булды.

7 нче зөлкагъдә – Биъре Габбәстә безгә Мәккәдән чыккан бер кәрван очрады. Янбугъ белән Мәдинә арасында юл бик тигез, хәтта тимер юлы салып, трамвай йөртергә дә бик мөмкин һәм уңайлы. Юл читендә калган гарәп авылларында укылган иртәнге намаз азаннары яңгырап, безгә дә ишетелеп торды.

11 нче зөлкагъдә – Мәдинәгә җитеп, Корбангали хаҗи[20] такыясенә килеп төштек. Мине носилкага утыртып, дурт кеше күтәреп алып керде.

Мәдинә

13 нче зөлкагъдә – дүшәмбе өйлә намазы алдыннан мөкатдәс Пәйгамбәр мәчетенә бардым. Михрабка якын бер урында ике рәкәгать намаз укып, Пәйгамбәрнең изге кабере янына һәм башка изге урыннарга барып килдем. Аннары мәчеттәге терәк баганаларының берсе астында утырып, бераз хәл җыйдым. Ярым сәгатьтән азан укылды. Михрабка якын бер урында намаз укыдым.

17 нче зөлкагъдә – иртәнге намазга бардым. Шәфигый, мәлики, хәнәфиләр бер җәмәгать булып, һәрберсе намазын үз

[20] Казанның атаклы сәүдәгәрләреннән – Корбангали бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Йосыф бине Борнай. Гыйлем һәм мал иясе иде. Мәдинәдә үзенең аерым төзелгән йорты булмаса да, барлык кунакларны бушлай кунак иткән зур такыясе бар иде. 1266 елда хаҗ кылып, 1275 елда вафат булып, Казанда күмелгән.

рәвешенчә укыды. Җомга хөтбәсенең һәр ике өлешендә дә «أَمَّا بَعْدُ» әйтелеп, хәлифәләр хөтбәнең икенчесендә искә алынды.

20 нче зөлкагъдә – Гыйззәтулла бине Габделмәҗид Әш-Шәрданинең чакыруы буенча кунакка бардык. Безне бик тәмле пылау, әйрән, ит һәм чәй белән сыйлап, кунак итте. Истанбулдан чыкканнан бирле мондый ләззәтле нигъмәтләрне ашаганыбыз булмады. Ул көнне, ахшам намазы алдыннан, мин – күп гөнаһ һәм кимчелек иясе бер фәкыйрь – ак күлмәк киеп, билемә яулык бәйләп, Пәйгамбәр бүлмәсенә кердем. Берничә шәм яндырдым. Расүли Әкрам әфәндебез (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) белән хәзрәти Фатыймага сәлам биреп, дога кылып чыктым. Изге мәчеткә хатыннар да килә икән.

22 нче зөлкагъдә – Мәдинәнең «Баб Әш-Шәм» исемле капкасыннан чыгып, хәзрәти Госман коесына бардык. Ул урынга Сүриядән килә торган кәрванны каршы алырга Мәдинәнең башлыгы Сафи Паша да килгән иде. Яхшы келәмнәр җәелгән иде. Мәккәдән җибәрелгән билгеле Габделмотталиб нәселенең вәкиле дә шул кәрванны каршылап, көтеп утырып тора иде. Бу кеше үзе дә затлы нәселдән булып, Габделмотталиб гаиләсенең кияүе дә иде. Сафи Паша белән күрештек. Келәмгә утырып, безне каһвә белән сыйлады. Шушы мәҗлеснең мәһабәтлегенә күңелем тулды. Үземне кулда тота алмыйча еладым.

Мәдинә шәһәре тигез, таулар һәм кыялар булмаган урында урнашкан. Туфрагы кызгылт, ләкин каты түгел. Һавасы хуш һәм мөлаем. Арпа һәм ясмык кебек нәрсәләр чәчеп үстерәләр. Мәдинәдә муллык. Анар һәм хөрмәләре бик югары сыйфатлы. Икмәк бик арзан. Ит очсыз. Катык ләззәтле, сөт күп. Төрек лирасы белән санаганда, Истанбулның бер тиене монда тиен

ярымлык кыйммәткә ия. Сүрия кәрванының атлары бик яхшы, дөяләре бик эре булып чыкты. Паланкин һәм башка нәрсәләре дә сокландыргыч матур иде. Мәдинәдәге барлык изге урыннарны һәм каберләрне йөреп чыгып, догалар кылдык. Дус һәм танышларыбызда кунакта булдык. Мәдинәнең олылары белән күрешеп сөйләшеп, үзебез өчен яңа нәрсәләр ачып, вакытны файдага үткәрдек. Болардан – Хәсән Фәһми бине Госман Әбү Хәйдәр[21], шәех Мөхәммәд Мәзһәр бине Әхмәт Сәгыйт Әл-Һинди Әл-Хәнәфи[22], аннары шәех Ахунджан бине Габделһади Әл-Бохари[23]. Шулай ук Ибраһим әфәнде шәех Габделҗәлил Әл-Мәдәни, Габделкадир бине Әхмәт Әл-Хәнәфи Әт-Траблүси, мөфти Мөхәммәд Әр-Рубали. Киләр мәдрәсәсенең мөдире Муса әфәнде, шәех Хәлил бине Ибраһим әфәнде, Мөхәммәд Гыймадетдин Ән-Нуркәи һәм башкалар. Җомга намазыннан соң шәех Мәзхәр хәзрәтләре изге кабер каршысына басып, минем өчен хәерле дога кылды.

25 нче зөлкагъдә – Сүрия кәрваны белән Мәдинәдән аерылып, юлга чыктык. Зөлхәлифә[24] дигән урында ихрам кидек. Сәгыйт Паша кәрвандагыларның хаҗ әмире итеп билгеләнгән иде. Кәрван туктар һәм кузгалыр алдыннан һәм һәр намаз алдыннан туп аталар иде. Төннәрен безне каравыллап, гаскәр саклап тора иде.

---

[21] Бу кемсә – Шәех Әл-Исламнарның берсе. Үзе турында без инде аңлаткан идек.

[22] Нәкшебәндия шәехләренең билгелесе һәм мәшһүре. 1301 елда вафат була.

[23] Бу кемсә – галим һәм билгеле бер шәхес, хәзер дә сау-сәламәт икәнлеге билгеле.

[24] Бу урынны хәзрәти Галигә атап, «Гали коесы» – дип тә атыйлар.

28 нче зөлкагъдә – (21 октябрь) Җиддәне уздык. Монда хөрмә бакчалары күп, манаралы мәчетләр бар. Ул көнне бик эссе булды. Кап эчендәге каты шәмнәр эреде. Комган һәм ләгәннәр тоталмаслык дәрәҗәдә кызды.

29 нчы зөлкагъдә – Сафра белән Бәдерне уздык. Сафрада хөрмәлекләр күп, мәчетләр бар. Безгә күп нәрсә китереп саттылар. Бәдердә балык сатып йөргәннәрен күргәч, диңгезгә якын, дип уйладык. Бәдерне узгач, уң ягыбыздагы таулар бетте, сул тарафтагылары ерагая калды. Аяк асты комга әйләнде. Җил алып килгән һавада диңгез исе сизелә иде. 3 нче зөлхиҗҗә көне (25 нче октябрь) Рабигъка килеп җиттек. Хатын-кызлары һәм бөтен халкы кәрванны каршыларга чыккан иде. Гаскәриләр музыка уйнап керде. Базарларында кәрвандагылар өчен кирәк нәрсә күп булды. Бу Рабигъ Сүриядәге Җүхнә[25] белән бер озынлыкта ята икән. Шуның өчен Мәдинә халкының күбесе бу урында да мәхрәм була икән. Болай эшләүнең дөреслегенә дәлил Әбү Хәнифәдән (рахимәһуллаһ) килгән риваятьтә дә бар икән. Без Фатыйма үзәнлеге дигән урында туктаган вакытыбызда, болытлар куерып, каты җил чыкты. Күк күкрәп, яшен яшьнәде, бераз яңгыр да яуды. 7 нче зөлхиҗҗә – (29 нчы октябрь) чәршәмбе көнне Мәккәгә кердек.

---

[25] Бу шәһәрнең элеккеге исеме Мәһия иде.

Мәккә

Кирәк һәм тиешле булган барлык хаҗ йолаларын исән-имин үтәп чыктык.

10 нчы зөлхиҗҗә – без ихрамнан чыктык. Моңа карамастан, кайбер гарәп булмаган милләт вәкилләре бездән соң да әле бер көн Гәрафәттә калып, ихрамнан 11 нче зөлхиҗҗә генә чыктылар. Мөхтәрәм Габделмотталиб хәзрәтләре халык арасына чыгып, салмак кына атлап, халык белән күрешеп йөри иде. Барган урында гаскәриләр аны туп атып һәм музыка уйнап каршылыйлар иде. Мәсҗед Әл-Харамга «Баб Әл-Гатикъ» исемле капкадан кергәндә, уникe баскыч аска төшәсе бар. Кәгъбәтуллаһның Йәмән почмагы көньякка карый. Хаҗ вакытында мөкатдәс мәчетләрнең икесендә дә ахшам намазы алдыннан шәм яндырып куялар. Мәккәдәге Бәйтуллада шәмнәрне төне буена калдырып, иртәнге намаздан соң гына сүндерәләр. Иртәнге намазны шәфигый, мәлики, хәнбәли һәм хәнәфиләр шушындый тәртип белән укый: хәнбәлиләр, гадәттә, аз булалар һәм Мәккәдә генә иртәнге намазны аерым үзләре укыйлар. Мәликиләр дә кайбер намазларын гына аерым укый, башка вакытларны күбрәк хәнәфиләргә ияреп укыйлар. Мәдинәдә хәнбәлиләр өчен махсус җәмәгать намазы юк. Хәнәфи һәм мәлики мөәзиннәре рөкүгътан кайтканда, кычкрып «سَمِعَ اللهُ لِمَنْ حَمِدَهُ», – диләр, шәфигыйларда – «رَبَّنَا لَكَ الْحَمْدُ» – диләр. Мәлики һәм шәфигыйләр икамәт сүзләрен берәр тапкыр гына әйтә, мәликиләр кыямда кулларын аска төшереп басып тора, шәфигыйләр – кулларын күкрәк өстендә баглап тота һәм рөкүгътан кайтканда кулларын күтәрәләр. Иртәнге намазның икенче рәкәгатендә рөкүгътан соң «اَللّٰهُمَّ

«اِهْدِنِي...» – дип башланган «Конут» догасын кычкырып укыйлар. Моннан тыш, имам укыган сүрәләрне артыннан кабатлап, укып барырлар. Әмма шигыйлар – тәкбирләрен кычкырып әйтеп, кулларын колак йомшагына кадәр күтәрәләр. Тәкбирдән соң кулларын баглап, кычкырып укыла торган намазларда «бисмилләһне» «Фатихә» сүрәсе һәм башка сүрәләр алдыннан кычкырып әйтәләр. Иртәнге намазның һәр ике рәкәгатендә дә «Ихлас» сүрәсен укыйлар. Рөкүгътә өч тапкыр «سُبْحَنَ رَبِّيَ الْأَعْلَى وَ بِحَمْدِهِ» – диләр, сәҗдәдә: «سُبْحَنَ الله. اَللَّهُمَّ صَلِّى عَلَى مُحَمَّد وَآلِهِ», – диеп әйтәләр. Сәҗдәдән торганда кулларын бераз күтәрәләр. Корьән укулары сарт таҗикларыныкы кебек зәгыйфь. Һәр аятьтән соң туктап алалар. Азан әйткәннәрен, сөннәт һәм витр намазларын укыганнарын күрмәдем[26].

19 нчы зөлхиҗҗә – дүшәмбе кич ясту намазыннан соң, мин – фәкыйрь, Фәйзулла һәм Зәйнулла белән бергә Кәгъбәтулла эченә керү мөмкинлеге белән хөрмәтләндек. Мәккәдә мин Мөхәммәд бине Гали бине ИбраһимӘн-Нәзили, Рәхмәтулла бине Хәлил бине Әр-Рахмән Әл-Һинди, Мөхәммәд бине Әхмәт Әл-Коньяви белән күрештем. Мөхәммәд Әхмәт Әл-Коньяви мине үзе эзләп тапты, күптән күрешеп, сөйләшәсем килә иде, диеп. Казан һәм Бохара галимнәре турында һәм башка күп нәрсә турында сорашты. Минем белән гарәпчә сөйләште, кыяфәте һәм рәвеше гарәп галимнәренекенә бик охшаган иде. Әмма шәех Рәхмәтулланы күрү өчен мәдрәсәсенә махсус бардым. Үзем белән кардәшем Садретдинне һәм Тауиленең Камалетдинын да ияртеп алып барган идем. Нәҗметдин,

[26] Без укыган шигый китапларда азан һәм икамәт сөннәт гыйбәдәте итеп аңлатыла. Ләкин шигый азан һәм икамәттә бераз аермалар бар. Боларны төгәл белү өчен үзләренең китапларына мөрәҗәгать итү кирәк.

Салахетдин һәм Тарханлы Зыяэтдин Әхмәт[27] әфәнделәр дә безнең белән бергә барганнар иде. Рәхмәтулла әфәнде безне бик шатланып кабул итте. Чәй әзерләттерде. Безгә «сәет» диеп кенә мөрәҗәгать итте. Әңгәмәбез күңелгә хуш, мәҗлесебез гаять файдалы булды. Үзе гарәпчә һәм фарсыча сөйләште. Миңа «Изаләт Әл-Әүһәм» китабының бер нөсхәсен һәм «Изхар Әл-Хакк»[28] китабының биш нөсхәсен бүләк итеп бирде. «Изхар Әл-Хакк» китабының дүрт нөсхәсен тиешле кешеләргә бирерсез, калган нөсхәсе бездән сезгә ядкәр булсын», – диде.

Кайту

25 нче зөлхиҗҗә – ахшам намазыннан соң Мәккә белән саубуллашып киттек. Бер сәгать кадәр җәяү бардык. Икенче көнне Җиддәгә барып җитеп, «Кайсәрия» исемле дәүләт пароходына кереп урнаштык. Өч көннән соң юлга кузгалдык.

27 нче зөлхиҗҗә – Синай ярымутравындагы Әт-Тур шәһәренә барып җиттек. Монда хаҗдан кайтучыларны карантин өчен пароходтан төшерделәр. Әт-Тур шәһәре Җиддәдән килгәндә уң якта, искиткеч матур диңгез буенда урнашкан бер Мисыр шәһәре. Бер-ике таш бинасы бар. Шәһәрне саклау өчен бер гарнизон гарәп гаскәре белән бер көймә тора. Ике көннән карантин тәмамланып, яңадан юлга чыктык. Юлда, каютабызга бер кызылбаш шигые кереп, Коръән мөсхәфен

---

[27] Әхмәт Зыяэтдин Шәмсетдин Әт-Тарханиның улы. Габденнасыйр бине Мөхәммәд Әл-Буави шәкертләренең берсе. 1307 елның Зөлхиҗҗә аенда 39 яшендә Мәккәдә вафат була. Мөхтәрәм шәхес, шагыйрь һәм язучы кеше иде.

[28] «Изхар Әл-Хакк» китабы төркичәгә, французчага һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән иде.

чыгарып:{هُوالَّذِي خَلَقَ ٱلْأَزْوَجَ كُلَهَا وَ جَعَلَ لَكُمْ مِنَ ٱلْفُلْكِ وَ ٱلْأَنْعَامِ مَا تَرْكَبُونَ} аятен күрсәтеп, бездән тәфсирен сорады. Миннән ишеткән җавап белән канәгать калып чыгып китте. Әмма намазларын үз мәзһәбләренчә дөрес укыгач, догаларын дөрес кылгач һәм Коръән аятьләрен тиешле урында укыгач, мин ул кешене галимдер диеп уйладым, шуңа күрә дә болай сорауның үзенә кирәклеге яки кирәксезлеге турында безгә берни мәгълүм түгел. Суэц, Исмәгыйлия, Порт Сәит шәһәрләрен узып киттек.

12 нче мөхәррам 1298 ел – Измиргә килеп җиттек. Измирдә төшәчәк хаҗиләр әйберләрен туплап, урыннарыннан кузгалып: «Инде кайтып җиттек, тиздән төшәбез», – диеп шатланышканда, карантин игълан ителде. Моны ишеткәч, халыкның күңеле бераз төште. Һич көтмәгәндә шундый мәшәкать килеп чыкканга бик күңелсезләнделәр. Бигрәк тә безнең Зәйнулла хаҗи иптәшебез хафаланды: «Болай булгач, хаҗи саналмам инде мин, кибетемне башкасы алыр», – диеп борчылды. Пароходыбызны карантинга куюларының сәбәбе – бездән алда килгән инглиз пароходының инде карантинда торуында иде. Бер пароходны карантинда тотып, соңыннан килгәнен җибәрү уңай күрелмичә, «Кайсәрия»не дә карантинга куйдылар. Хәлбүки, «Кайсәрия»дәге хаҗиларның күпчелеге сау-сәләмәт булса, инглиз пароходындагыларның күпчелеге авыруга сабышкан иде. Моның сәбәбе дә – хаҗиларга начар һәм бозык су эчереп, аларны яңгыр һәм суыктан саклый белмәүдә иде. Шулай итеп безне дә 48 сәгатькә пароходыбыздан төшерделәр, әмма мин һәм башка кайберәүләр пароходта калдык. Мәгълүм вакыт узгач, юлыбызны дәвам иттек.

14 нче мөхәррам – җомга көн кич белән ай тотылуын күзәттек. Хосуф намазын укыдык. Мин бинокль белән карап барганга һәм пароходыбыз коры җиргә якын барганга, диңгез буендагы авыллар һәм бакчалар күренеп кала иде.

16 нчы мөхәррам – Галиболуны узып, сул ягыбызда калдырып киттек. Мәчетләре күренеп калды. Безнең күрше каютада Мөхәммәд исемле бер Зәнҗан кешесе барды. Киеме гарәпләрнекенә охшаган булса да, теле төрки иде. Үзен шәфигый мәзһәбеннән дигән булса да, сөнниләргә дә, шигыйларга да һич катышмады. Тәбриз кызылбашларыннан бу кеше турында сорагач, Зәнҗанда имам, диделәр. Өстәл артында бер китап укып барганын күргәч, арабызда шундый әңгәмә узды:

Мин: «Бу нинди китап?»

Зәнҗанлы: «Гыйбәр».

Мин: «Шиһабетдин Әл-Гәскалани[29] китабымы?»

Зәнҗанлы: «Юк, түгел».

Мин: «Нинди фән турында?»

Зәнҗанлы: «Тарих».

Мин: «Алайса, Ибне Халидунның[30] «عُنْوَان ٱلْعِبَر و دِيوَان ٱلْمُبْتَدَاءِ وَٱلْخَبَر فِي أَخْبَارِ ٱلْعَرَب وَٱلْعَجَم وَٱلْبَرْبَر» китабы булса кирәк».

Зәнҗанлы: «Әйе. Бу китап сездә бармы?»

Мин: «Күп нөсхәләре бар».

---

29 Бу кемсә – Әбү Фәдл Шиһабетдин Әхмәт бине Гали Әл-Гәскалани Әш-Шәфигый. 852 елда Мисырда вафат. Язган китаплары күп булса да, «Гыйбәр» исемле китабы барлыгын күрмәдем. Шуның өчен мөхтәрәм Мәрҗанинең мондый сорау бируенең сәбәбе безгә билгеле түгел.

30 Әбү Зәед Габдерахман бине Мөхәммәд. 806 елда вафат. Бу шәхеснең биографиясен белү – үзе бер гыйлем.

Минем бу сүземә, китапның беренче томында аңлатылган һәм сәхабәләр арасында фикер каршылыгы тудырган бер нәрсәнең мәгънәсен аңлап бетерә алмаганлыны турында сөйләп, шул урынны табып, миңа күрсәтү өчен китапны озак-озак актарды, әмма таба алмады. Хаҗи Зәйнулла ул кеше үзен бик кибәранә тота ди. «Халык мине танымый, исемемне белми, әмма Истанбулга баргач, сукыр Сөләйманны[31] танытырмын мин аларга!» – диеп сөйләнгәнлеген әйтте. Бу кеше Габделхәмит Әл-Бохари Әл-Кызылярый исемле бер Коръән укучысына очрагач, кайдан икәнлеген сораган. Тегесе Ташкенттан дигәч: «Ташкент һәм Бохара халкы мөселман булган хәлдә, шигыйлар белән мөселманча хисаплашмауны нинди намус белән дөрес диеп күрәләр микән?!» – дигән бәхәс башлады. Тегесе: «Шигыйлар сәхабәләрне сүгеп, имансызлыкка кайталар, шул сәбәпле, алар белән хисаплашмау да дөрестер[32]», – дип әйткән. Бу кеше: «Алай эшләсәләр мөртәт кенә булалар, мөртәт белән имансызлар кебек хисаплашу бик үк дөрес түгел!» – диеп, теге кешегә үз фикерен кабул иттерергә тырышты. Мөселман галимнәре чыгарган уртак карарларның да хөкем көче барлыгын инкяр иткән ул Зәнҗанлыга мулла Мостафа сүз әйтеп караса да: «Сездә гыйлем юк, бар эшегез – кабатлау һәм сукыр иярүдер!» – дигән җавап кына ишетте.

17 нче мөхәррам – Истанбулга килеп җиттек.

---

[31] Сукыр Сәлим хикәясен белгән кеше бу сүзләрнең хикмәтен дә яхшы аңлар.

[32] Бу мәсьәләдә алай иркен сөйләшү дөрес түгел, чөнки шигыйлыкта сәхабәләрне сүгү тиешле гамәл түгел һәм араларында сәхабәләргә тел тидермәүчеләр бик күп. Мәсьәләне аларның үз китаплары белән танышып, шул гыйлемгә нигезләнеп чишәргә кирәк.

Икенче мәртәбә Истанбулда

Бер кибеттә Кокандлы Мирза Габдерәхим исемле кешене очратып, Ходаяр-хан хәбәрләрен сораштым: «Хәзерге вакытта Багдадта ул», – диде.

19 нчы мөхәррам – Мөниф Паша белән күрешеп, озын-озак сөйләшеп утырдык. Бик югары әхлаклы һәм камил кеше икән. Биш төрле телдә җиңелчә аңлаша алганы турында сөйләде. Гарәп һәм фарсы телләрендә оста сөйләшкәнлеген без дә бәяләдек. Хәтта берсе – сигез, икенчесе дүрт яшьлек ике улы да фарсыча белгәннәре билгеле булды. Олы улына фарсы телендә: «Әфәнденең кулын үп», – дигәч, яныма үзе килеп кулымны үпте. Кече улы белән фарсы телендә шушындый әңгәмә уздырды:

Паша: «Нәрсә телисең?»

Бала: «Бакыр акча».

Паша: «Бакыр акчамы, алтынмы?»

Бала: «Бакыр акча».

Паша: «Алтын акча алмыйсыңмыни?»

Бала: «Алам».

Өендә ике аягында басып торган зур аю карачкысы бар иде. Моны рус императоры ауда атып үтерде диде. Бу карачкыны император башта Төркиянең Санкт-Петербургтагы илчесенә – Хәлил Пашага бүләк итеп бирде, соңыннан Хәлил Паша Мөниф Пашага бүләк итте, диде. Өенең түбән катында ашап-эчтек, аннары өске катына менеп каһвә-чәйләр эчтек. Өендәге

әйберләр бик бай һәм кыйммәтле[33]. Алтынланган өстәл һәм урындыклар, мәрмәрдән ясалган хатын-кыз сыннарын күреп, шаккаттык. Безнең бу хосуста ни хәтле мәгълүматлы булганыбызны белү өчендер бәлки: «Сезнең фикерегезчә, моның кыйммәте күпме?» – диеп сорады. Аннары үзе үк: «Җиде мең тәңкә», – диеп, җавабын да бирде. Кайчак гарәпчә, кайчак фарсыча һәм төрекчә сөйләште. Миңа «سِر اللّيَال فِي ٱلْقَلْبِ وٱلإِبْدَال» һәм «Бразилиягә сәяхәт» исемле китапларын бүләк итте. Без өендә кунак булып утырган вакытта янына керер-чыгучы кеше дә күп булды. Болар арасында кайбер мөхтәрәм һәм олы затлар да күренде. Киткәндә, безне озатып ишеккә хәтле барды. «Сезгә нинди генә китап кирәк булса да, миңа моның турында хат языгыз, сезгә шуны һич кичекмәстән җибәрермен», – диде.

20 нче мөхәррам – сәет Гәвен бине Мөхәммәд бине Гәвен шәриф хәзрәтләрен күрергә бардым. Янында Садыйк Пашаның[34] вәкиле дә бар иде. Тагы бер ак сакаллы кеше килеп, шәрифнең кул һәм чапан итәген үпте. Шәриф хәзрәтләре бу кешегә «галиҗәнәп хәзрәтләре» диеп кенә эндәште. Соңыннан бу кешенең исеме Гыйззәт әфәнде икәнлеген белдем. Ачы каһвә белән сыйландык.

Безне озатканда, шәриф хәзрәтләре ишек тоткасын үзе тотып торды.

---

33 Артык кыйммәтле яшәү рәвеше модасы Казанда да инде таралганлыгын ишетеп беләбез.

34 Тунисның дәүләт башлыгы Садыйк Паша бине Әл-Хөсәен турында әйтелә. 1222 елда туып, 1297 елда 75 яшендә вафат була. Урынына Гали исемле туганы килеп, француз протектораты астында идарә итә.

21 нче мөхәррам – пароходка утырып, Истанбулдан киттек. Өченче көнгә без инде Одессада идек һәм шул ук көнне машинага утырып киттек.

27 нче мөхәррам – Нижнийга җиттек, анда почтаның атлы чанасына утырып, Казанга таба юл алдык.

30 нчы мөхәррам (20 декабрь) – шимбә көн икенде намазы алдыннан Казанга кайтып җиттек. Беренче мәчет ишеге алдында дуслар һәм танышлар белән исәнләшеп күрештек. Мәчеткә кереп, икенде намазын укып, гаиләбез янына кайтып киттек. Хатын һәм балалар белән күрешеп, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт һәм мактаулар әйттек.

Шиһабетдин Мәрҗанинең кыскача биографиясе

Шиһабетдин Һарун бине Бахаэтдин бине Сөбхан бине Габделкәрим Әл-Мәрҗани Әл-Казани (рахимәһуллаһи) 1233 елның 7 нче рабигыль-әүвәл аенда дөньяга килде. Заманасының иң игътибарлы галимнәре, иң бөек мәшәехләре белән күрешеп, гыйлемнәреннән күп файда алды. 1265 елда Казан шәһәренә килеп, беренче мәчеттә имам, хатыйб, мөдәррис, мөхтәсиб һәм ахунд вазифаларында эшләде. 1306 елның 28 нче шәгъбанында, 74 яшендә бу дөньядан китте. Казан зиратында күмелгән.

Кешенең гомере булса да мең ел,

Бер төн артык булмас бу галәмдә кунак.

Шиһабетдин ахунд хәзрәт ачык йөзле, эре гәүдәле, күркәм сүзле һәм төпле фикерле кеше иде. Ул бик яхшы ис-

лам гыйлемнәрен, тарих һәм әдәбиятны белә иде. Гарәпчә шигырьләр, «Кәшшәф», «Бәйдауи», «Мәдәрик» һәм «Ихъйә» кебек олы әсәрләрнең күп өлешләрен яттан белә иде. Аның һөнәре – ислам китапларын тәнкыйтьләп, шул рәвештә халкына хезмәт итү иде. Мондый юлдан йөргәннәрнең нинди авырлык һәм кыенлыклар белән очрашачаклары билгеле. Шуңа күрә ул да замана ачылыкларын үзендә татыды һәм аларга түзде. Тирән фикерләрен чагылдырган аның үткен каләме ул үлгәнчегә хәтле аңа баһадирлар данын яулады.

Милләт һәм халкыбызга хезмәт итү фикере белән янган хөрмәтле дус һәм кардәшләребезгә аның тормышы һәрвакыт күрсәткеч һәм үрнәк булыр.

Ризаэтдин Фәхретдин

... السلام اننکه سمرقند تنکه داخلنده خواجه عبید الله
احرار مسجد سمد العمرده بر مصحف قدیم بار ایدی

جلد حیوانه یازلغان خطا کوفه برله حرکاتسز نسقطسز
وثناه وعلامات وقوف وایات دالسیما کسعور دعشر ذلک
دن هیچ بر نرسه یوق صفحه لرننک قوبنده تنقیص ایتکنده ...
عثمانه بر قزل رنک بار آیه قان ایمش دیلر نسول قران ...
مصاحف احضرت عثمان ننک اوز بینه تخصوص امام دیکله معروف
مصحف دیب سمرقند بخارا اهالی سی ... الیه لر نسول مصحف ...
روسیه لر سمرقنده استیلا ایتدکلر ندن ... بطر بورغغه
الیب کلدیلر ... کرات مراسته بیک ... اهلی ایدیلر

کردم یازدیلر اول مسلمانلر ننک مصحفی اوللری لیغ بر ...
نسخه لری ... اوزلری ننک ... اکر ... اوقی ... در
دیب یازدیلر اول مصحف بر ... ظنلر ... آثار ... دن
اولسه ... مصحف امام ایمس ... سمرقنده ...

در ... مدت ... قراءت اوقدم ... تاریخ دن ۱۵ سنه مقدم ...
السلاف ... یازدی ... ۱۲۵ ... آثار ... وفات ایدان ملا عبد الرحیم
بن عثمان الاوتز ... ترجمه ... بتعر ... ذکر ...

حاصل ... بیان ایتمش ایدم الوقت اول ترجمه ...
تمام ... یازدیم ... اولسه ... لره ... مجموعة
الفنون لره درجله طبع ایتدرسه ... بولور ایدی
چونکه آنلن روسیه لرننک ... لرینه جواب ...
... اولدقی ... مصحف اول ایمس ... ناظرلار
الحمد ... ایدیم ... دیب یازا ...
... ترجمه ایدکان ایدی ... ایدی

[illegible]

مرجانی زاده قول یازمالاری.

رضا زننک مدرسه خصوصنده تحریر قلنغان بر رساله مسوده سی بار ایدی اکا بیاض
لوب باصدرمق اراده سنده ایدی. بیچاره بیاضنه فرصتی بولمادی هر در شغول رساله
یازلماسه ایکان من اوزم اونی بیاضنه چقاروب باصدرمق قصدنده بولور
دم لار آخل تعدد نسخ بولورلق بشی التی نسخه یازدردم ایردیم بیچاره نینک
ی و اجتهادی ضایع بولماسه ایکان اول بیک نخت بیک مفید نرسه ایدی
ام خلقی نماغه ارا جیف تلدسه لار ینه سورلدسون لار جاهل و عداوت و حسد
سبب لی کوترسه لار افترا قیلوب شایع ایته لار اول معتبر ته کل ماده حسنله
ارف غیر متعارف دور منم اوزم عندمده یکرمی یل بخاراده درس اوقوب یوز
سوزنده قاییتوب یکرمی سنه درس ایتکان کتبی لار نشوونا اعتبار بیرله مطالعه و محل حفظ
سه لار اتالاری بابالارینه میسر بولماغان علم لکی حاصل ایتالار ایردی
ملمی کرک جاهل حاسد حقنه عمر جفا قیلمای غضب عدوان سی بیرله افترا و بهتان قیدا
ور تحصیلنه عدد صالنه دور والله مستعان انه خیر من اعان حاصل کلام ممکن بولسه
ولکن ایله مرحوم دن قالغان کتاب لارنی اسم لارنی یازیب آلوب تفصیلا فهرس یا صلوب
بایاغی رساله سینی و نهشونکار متعلق جبزی کاغذ لارده بولغان تحریر لارنی هم بر
سز مقدمه رک اوزی نینک جمع قیلغان بر مجمعی بولسه کرک ایدی ینه تاتار تلنده
حرفی بولسه کرک ایدی بلغار و قزان حقنده مقالداسی بولسه کرک ایدی هر نه
نینک هم شمعونی خط بیلان جماعتنه افاده ایده سز والسلام بجنب مخدوم سلا
استقراء سببیتی خیر الاستمقام ... ادراک ایدی . اولمی کیا کی صادقی اوزنه بردن سلا
خالی لیس من جمادی الاخیرة سنه ١٢٨٣ کتبه عبد الله شهاب الدین بن بهاء الدین المرجانی

بسم الله الرحمن الرحیم

برادر گرامی عزیز القدر گرامی ملا سلیم الله غه جمیع اهل بیت و هواخواه و مستندلارینگز با شمول ادعیه لائقه
وند تحفه لاریمز. بو ابلاغ ایدوله بعد السلام سنة الاسلام جانب فقیرلاری مع جمیع مستندان مصحوب صحت و تندرستی
سلامت کا کان تصدور ایدوله طرفینگزدین مرسول مکتوب مزالت اسلوبینگز بو تینگه تصدق قنگزه مع اوله
رنی تسلیم اولوب حقینگزده دعاء خیر قلیندی قبول عند الله اولدر. های مشاینم ملا حسین مرحوم وفات بولغان
ایکان لار بالسه بو تلای تقدیرکا مطیع بولای بو چاره مز بار الله تعالی غریق رحمت ایلب مسکنینی بحبوحه
جنت ده ایلیدکای ایدی کوب کوب خدمت لار قیلیب با زیاده فائده لار بیتکورکان ایدی اجر جزیل و ثنا
جمیل بیرمکده جزاء خیر باری جل و علاکه حواله قیلیماساق المرد لا غیر باکیلوب انیا هنگو بنی و حزنا
الی الله بزکا بیک ادوار شکسته بولدی ان الکرام قلیلة الاعمار حاضرده هر بر جهت بر لان علم عمل و هم عقل
فراست و بصیرت و دیانت جهتیدین فایدا اننگ مثلنی تاباج بیک صعب ایدی اوب تا بولور تا بولسه هم
بی نهایه مصیبت کنمی ایدی الحیف عامة الناس کا اعتبار ایوق نفس مرده بیک مصیبت کیتیج ایدی
الله تعالی اخرتینی معمور و اولاد لریغه خیرلی معیشت لار عطا قیلیلشو بیچارا قالیلدام بیک خفا بولغان
لار دور سبب معیشت ماده توکل بولدر ایک الشلدری بار دی ایکان الله تعالی اوزی فضل کرمی برله
اسباب حسنه بندگانه عطا ایلیه آمین اول بیچاره لار ننگ احوال حالیغه غم عنگز. تدارکه بزکا هم خطینگزده
ده تفصیل بیان قیلما قنگز. مامول دور شرح عقاید نی بز اوقرنیه تعبیه قیلیغان ایدوکز ابزکا
ممکن امیس ایکن کما اهل قولینه تهنشوب با قدر بولماسه ایکان تیبونش ایمکنی بیر دیب اورنینگ الی بز
بحوک بولور ایکان بینه آنینگ هر تورلی مجموع لری و کتاب لاری بولسه کیرک ایدی بزکا قول
کتاب لاری بولغانده صاتمون نه اختیار قیلیه لار بز بلکه آلور ایردیک خصوص صا ایام
ازناس و تواریخ و احوال عالم کا تعلقلی لیامی بولسه بزکا ضرور ایدی

فاضل مرجانی‌نینك قسقه‌چه ترجمه‌سی

شهاب الدین هارون بن بهاءالدین بن سبحان بن عبدالکریم المرجانی القزانی البلغاری رحمه‌الله تعالی ۱۲۳۳ سنه‌ده شهر ربیع الاول ۷ ده طوغمشدر، زمانه‌سی نینك معتبر عالملرندن استفاده ایدوب هرنیتلو مشائخ لـرنی کوروب صحبت ایتمشدر. (١٢٦٥) ده قزان شهرینه کیلوب برنچی مسجد محوره‌نده امام، خطیب، مدرس، محتسب آخوند، اولمشدر. (١٣٠٦) ده شعبان (٢٨) ده یتمش دورت یاشنده ایکان وقتنده بو عالم کا وداع ایلمشدر. قبری قزان مقبره‌سنده‌در. شعر، آدم‌نك عمری اگر بنك ییل اولورسه عاقبت دم کلور صان برکیچه عالم‌ده مهمان اولدامش، شهاب الدین حضرت آچق یوزلی. الوغ بدن‌لی؛ خوش سوزلی؛ وقارلی اوشنداق علوم اسلامیه‌ده ماهر، علم انشاء، تواریخ وادبیات‌ده حظی وافر اولمشدر. عرب شعرلرندن کوب شیلر، کشاف، بیضاوی، مدارك احیا، کبی اکابر اثرلرندن چوق نرسه‌لر حفظنده اولمشدر. کتب اسلامیه‌نی تنقید، واوزی‌نینك قومی ایچون خدمت ایلمك‌نی مسلك ایلمشدر. بیله یولده اولغان کمسنه‌لرنینك نه کبی مشقت‌لر ومحنت‌لر ایله مبتلا اوله‌چقاری معلوم‌در. شونینك ایچون بو ذات هم زمانه‌نینك بیك اچی تشلاولرنی کورمش لکن توزه‌مشدر. عالی فکری، ثباتلی قلمی ایله برلشوب تا اولکان کونه قدر بهادر عسکر کبی هرکت ایلمشدر. ملت وقوم‌نزکا خدمت ایلمك فکرنده اولغان هرمتاو دوست وقارنداشلرمزکا بوننك حالی هر وقت‌ده کوچرکچ واورناك اوله بیلور.

رضاء الدین بن فخرالدین

۲۵ ـ ده شریف حضرتلرینه (سید عون بن محمد بن عون) باردوم . بونك حضورنده صادق پاشانك (۱) وکیلی بار ایدی . دنی رآی ـ قالالی کشی کیلوب شریف ننك قول وایتاکارنی اوپدی . شریف حضرتلری بونکار ذات عالی نکزدیو خطاب ایدوب سوزلندی . صونکندن بیلدم بوکمسنه عزت افندی نامنده برذات ایمش . اچی قهوه ایچدوك .

کیتدکمز وقتده شریف حضرتلری ایشك طوتقه سنی طوتب طوردی .

۲۱ ـ ده استانبولدن واپورایله کیتدوك اوچونچی کونده ادیس ده اولوب شول کون هم ماشینه غه اولتوردوق .

۲۷ ـ ده نیژنوی کا یتوب ، وچته یعنی چانه وآت ایله قزانغه یوللاندوق .

۳۰ ـ ده (۲۵ کانون اول) شنبه کون ایکندی دن مقدم قزانغه قایتوب یتدوك . برنچی مسجد احاطه سنده دوستلر واهالی ایله کورشدوك . مسجدکا کروب ایکندی اوقوب خانه مزکا قایتدوم . اهل واولاد ایله کورشوب الله تعالی حضرتینه حمد وثناء ایتدوم .

بتدی

---

(۱) تونس ننك محمد صادق پشا بن الحسین در ولادتی ۱۲۲۲ سنه سنده اولوب یتمش بش یاشنده وفتنده ۱۲۹۷ سنه سنده تونس ده وفات در . اورنینه علی نام قارنداشی والی اولوب فرانسز حمایه سنی قبول ایلمشدر .

پاشا ــ چه می‌خواهی ؟

بالا ــ پول می خواهم .

بن ــ پول می خواهی یا پاره ؟!

بالا ــ پول می خواهم .

پاشا ــ پاره دهم نمی کری ؟!

بالا ــ می کرم .

خانه‌سنده بر الوغ آیو آیاق اوزرینه باسوب طوره ایدی . بونی روسیه ایمپراطوری آطقان ایمش . ایمپراطور طرفندن ، دولت علیه‌نینک پیتر بورغ ایلچیسی خلیل پاشاغه هدیه ایدلوب ، خلیل پاشا ایسه‌منیف پاشاغه ویرمش ایمش . خاده‌سی‌نینک توبان قاننده طعام یدوك . اوست قاتینه بنوب قهوه وچای ایچدوك . خانه اسبابی بیك مکلف ، تزو آلتونلی اوستال واورندق‌لر کوروب عجب ایتدوك (۱) . مرمر تاشندن اشلکان ، برخانون صورتی هم کوردك . بلکه بزنینک بوخصوصده اولغان معرفتمزنی بیلماك ایچون بولسه کرك ، بزدن « بو نه‌نینک‌چانوری » دیب سؤال ایتدی . صونکندن اوزی یدی بنك تنکه‌قیمتنده ایدوکنی بیان قیلدی . کاه عربی کاه فارسی کاه ترکی سوزلدی . « سر اللیال فی القلب والابدال » نام کتاب ایله ، بر از بیلیاسیاحت نامه‌سی » نام کتابنی هدیه ایدوب بنکا ویردی . بز بونینک خانه‌سنده ایکان وقتمزده کیلوب کروب چیقوچی کشی‌لر کوب اولدی . بونلر آراسنده بعض بر معتبر والوغ ذات‌لر کورلدی . کیتکان وقتمزده اوزانوب ایشککا قدر کیلدی . نه کتاب کرك اولسه‌ده مکتوب ایله بیان ایلسه‌نکز توقفسز کوندررمز دیدی .

---

(۱) سزدن صونك بوندای تکلف ومودالر ، قزانلی لرده هم ترقیده دیب ایشلامز

قاری تاشکندلی ' دیب جواب وبردکنده ' تاشکند هم بخارا خلقی مسلمان اولدوقاری حالده شیعه ارنی سانمق‌نی نه وجه ایله درست کوره‌لر دیو بحث ایلمش. قاری: شیعه‌لر صحابه‌لرنی سب ایدولری (۱) سبب‌لی کافر اوله‌لر ' شوننک ایچون سانمق درست دیدکنده آلای اولسه آنلر مرتد اوله‌لر. مرتدنی سانمق درست دگل دیب ' قاری‌نی الزام ایلمش. اجماع ننک حجة ایدوکنی انکار ایتدوکینه قارشو ملامصطفی سوزلب قاراسده ، سزده علم یوق ' بارهنرنکز تقلید ' دیمش (۲).

۱۷ — ده استانبول غه یتدوک.

ایکنچی مرتبه استانبول‌ده

بر دکانده خواقندلی میرزا عبد الرحیم اسملو کشینی کوردم آندن خدایار خان احوالنی صوراشدوم. حاضرنده بغداد ده دیدی.

۱۹ — ده منیف پاشاغه ملاقات ایتدوم. مجلسنده اوزاق وقت قالدوم. بیک فاضل وکامل ذات ایمش. بش تورلی لسان ایله سوزلرگا ماهر ایدوکنی بیان ایتدی. عرب ' فارسی لغتنده اولغان اقتدارنی بز هم بیلوب تحسین ایتدوک. حتی که بری سکز وایکنچسی دورت یاشده اولغان اوغللرینک فارسی بیلدوکلری معلوم اولدی. الوغ اوغلینه فارسچه « افندی ندک قولنی اوپ » دیدوکنده کلوب بنم قولمنی اوپدی. کیچی اوغلی ایله بیله سوز اولدی .

---

(۱) بو حق ده تیل‌نی ایرکن ببارەك مناسب دگلدر. چونکه بوشی شیعه‌لر قاشنده لازم عمل دگلدر. سکوت ایدوچی‌لری کوبدر. آنلر ننک اوز کتابلری ایله اشنا اولمغلقمز اقتضا ایدر.

(۲) بیك درست ایتکان.

بن ــ شهاب الدين العسقلانى (۱) اثرى ىى ؟

رنجانلى ــ يوق، دكل .

بن ــ قايو فندن ؟

رنجانلى ــ تاريخدن .

بن ــ آلاى ايسه، ابن خلدون (۲) ننك «عنوان العبر وديوان المبتداء والخبر فى اخبار العرب والعجم والبربر» نام كتابى اولور .

رنجانلى ــ بلى . بو كتاب سزده بارمى ؟

بن ــ كوب نسخه‌لرى بار . بوجوابمه قارشو اوّل جلدنده اصحاب اختلافى حقنده برسوزنى فضلاى آلمايمن، بلكه‌سن كوركان سن ديب كوركزمكچى بولوب كوب آقتاردى، اما تابا آلمادى . حاجى زين الله، اول كشى اوزنى بيك الوغ طوته‌در، خلق بنى هم بنم اسممنى بيلمايلر، اما استانبولغه بارغاچ صوقر سليمنى تانتورمن (۳)، ديب ايته‌در، ديو حكايت قيلدى بوكمسنه قارى عبد الحميد البخارى الغزلجارى غه اوچراب مملكتنى صوراەش .

(۱) بوكمسنه ابو الفضل شهاب الدين احمد بن على العسقلانى الشافعى اوله‌در ۸۵۲ ده مصرده وفات ايتمشدر . مصنفاتى كوب اولسه‌ده «عبر» اسملو كتاب بارلغى كورلمدى . شوننك ايچون فاضل مرجانى ننك بو سوءالى ننك سببى بزكه معلوم اولمدى .

(۲) ابو زيد عبد الرحمن بن محمد در . ۸۵٦ ده وفات در . بوكمسنه ننك ترجمه سنى بيلمك ده، الوغ علمدر .

(۳) تاريخ بيلكان كشيلركه بوننك بوسوزيننك حكمتى معلوم‌در .

واپوری کرانتین کا قویلغان ایمش . ایمدی آنی قویغان صونك قیصریه نی

هم قویه‌ق لازم کلمش . چونکه بر سنی قویوب ده ایکنچسنی آزاد ایلمك مناسب

کورلممش . حال بوکه قیصریه ده سلامتلك غالب اولدیغی حالده انکلیز

واپورنده خسته‌لك غالب اولمش . آننك ده سببی ایسه اوزیننك فناو بوزق

صولر ایچرتوب کیلوب ، حاجی‌لرنی یغموردن سافلای آلمای یوشلاتوب

صوق اثر ایدوی اولمش . قرق سکز ساعت مدت ایله کرانتین‌که چقاردیلر .

اما بعض کمسنه‌لر ایله بن قالدوم . معلوم مدت نی تمام ایدوب حرکت ایتدوك .

١٤ ـ ده جمعه کیچه سنده آی تمام طوتلدی . خسوف نمازی اوقدوق . هم

ناظوره ایله قاراب باردم . پاپور قوری‌غه یاقن باره ایدی . دینکز

بوینده بولغان قریه‌لر ، باقچه‌لر کورلوب قاله‌لر ایدی .

١٦ ـ ده کلیبولی‌نی صولده قالدروب اوتدوك . جامع‌لری کورلدی .

بزننك کورشی حجره‌مزده محمد اسملو بر زنجانلی بار ایدی . کیومی ایله

عرب‌که اوخشاغان اولسه‌ده تیلی ترکی ایدی . اوزنی شافعی مذهبنده دیگان

ایدی ، لکن سنی‌لرکه‌ده ، شیعی‌لرکه‌ده قاتوشمدی . تبریز قزلباشلری

بو کمسنه‌نی زنجانده امام دیدیلر . اوستالده بر کتاب مطالعه

ایدوب اولتورغانونی کوروب بوروش ده سوزلشدوك :

بن ـ بونه کتاب ؟

زنجانلی ـ عبر .

۲۷ ــ ده طورسیناغه یتدوك . بونده حاجیلرنی کرانتین ایچون چقاردیلر .
طورسیناء شاب دینکزی بوینده ؛ مصر تصرفنده . جـده‌دن کلکانده
اونك طرفی‌ده دور . ایکی اوچ عدد تاش بنالرهم کورلدر . ساقلار ایچون
عرب عسکری و بر واپورلاری توره‌در . ایکی کونده کرانتین مدتنی تمام
ایدوب کیتدوك . بر قزلباش بزننك حجره‌مزکا کروب اوزی ننك مصحفنی
چقاروب (هو الذی خلق الازواج کلها وجعل لکم من الفلك والانعام ماترکبون)
آیتنی کورکزوب تفسیرنی صورادی بن ایتکان صونك شونکار ضالق علامتی
کورکزوب چقدی. لکن بوکمسنه اوز مذهبلرنچه نمازنی رعایه ایدوب ،
دعالرنی درست اوقوب ، قرآن شریف آیةلرنی مناسب اورنلرنده
اوقدوقندن بخشی عالم دردیب حساب ایده ایدم . حاجت اولوبمی صورادی
حاجت اولمای می صورادی . معلوم اولمدی . سویس اسماعیلیه پورت
سعید . شهرلرندن اوتوب کیتدوك .
۱۲ محرمده (۱۲۹۸) ازمیرکا کیلدوك . ازمیرده توشه‌چك حاجـیلر ،
نرسه‌لرنی جیوب ، اورنلرندن کوچوب ، قایتوب یتدوك ، حاضر چقامز
دیب شادلانوب کیلدوکلرنده ، کرانتین ساقلامق لازم ایدوکی اعلام
ایدولدی . بونی ایشدوب خلق بیك مأیوس اولدیلر . آنکسزدن بوندای
مشقت چقوینه بیك کونکلسزلندیلر . خصوصا بزننك ایبداش زین الله
حاجی ، منزله‌دن قالورمن ، دکانم نی باشقه کشی آلور ، دیب خفالندی .
بوراحتسز خبرننك سببی بیله ایمش : بزدن مقدم کیلوب بر انکلیز
واپوری

ایله کورشدم . محمد بن احمد القونیوی اوزی ازلب کیلدی ، صحبت ایدرکا مشتاق ایدوم دیدی . قزان وبخارا علماسی و باشقه احوال حقنده کوب نرسه‌لر صورادی . عربی سوزلشه‌در . قیافتی و باشقه حاللری عرب علماسینه بیک اوخشاغان ایدی . اما شیخ رحمة الله‌ننک مدرسه سینه اوزه باروب کورشدم . برادرم صدرالدین‌نی تاوایلی‌ننک کمال الدین‌نی بولداش ایتکان ایدم . اوشنداق نجم الدین ، صلاح الدین طرخانلی ضیاءالدین بن احمد (۱) افندی‌لر دم برکا باردی‌لر . رحمة الله افندی شادلق وبیک ممنونیت ایله قبول ایتدی . چای حاضرلتدی . خطاب‌لرنی «سیدی» کلمه‌سی ایله قیلدی . صحبتمز خوش مجلسمز فائده‌لی اولدی . عرب وفارسی سوزلدی بر نسخه «ازالة الاوهام» وبیش نسخه «اظهار الحق» (۲) کتابلرنی هدیه ایتدی . اظهارننک دورت نسخه‌سنی مستحق کمسنه‌لرکا ویررسز قالغان ایکی نسخه‌سی بزدن اوزنکزکا یادکار اولسون دیدی

قایتمق

۲۵ — ده اخشام صونکنده مکه‌کا وداع ایدوب آیورلدوق . بر ساعت قدری پیاو باردوق . ایکنچی کون ده جده‌کا یتوب دولت علیه‌ننک قیصریه اسملو پاپورینه کردوک . اوچ کون صونک حرکت ایدوب کیتدوک .

---

(۱) احمد ضیاء الدین شمس الدین الطرخانی اوله‌در . عبدالنصیر بن محمد البوبی طلبه‌سندندر اوتوز توقز یاشنده وقتنده ذوالحجه‌ده بنک اوچیوز یدنچی سنه‌ده مکه‌ده وفات ایتمشدر . فاضل وشاعر هم ادیب بر ذات ایدی .

(۲) اظهار الحق نسخه‌سی ترکیچه وفرانسزچه و باشقه لسانلرغه هم ترجمه ایدلمشدر ا

مدینه‌ده حنبلی‌لرکا مخصوص جماعت نمازی یوق . حنفی ومالکی مؤذن‌لری «ربنا لك الحمد» وشافعی‌لر «سمع الله لمن حمده» دی‌لر . مالکی وشافعی‌لر قامت کلمه‌لرنی برارکنه ایتوب مالکی‌لر قیام‌ده قوللرنی ییاروب توره‌لر شافعی‌لر کوکراك آستوبنه باغلای‌لر هم رکوع غه بارغانده، قایتقانده قول کوتره‌لر وایرته نمازی‌نڭ ایکنچی رکعتنده رکوع صونکنده «اللهم اهدنی...» دیگان قنوت دعاسنی قچقرب اوقی‌لر . دخی امام آرتنده قرائت قیله‌لر . اما ایرانی‌لر ، تکبیرلرنی قچقروب آیتوب قوللرنی قولاق یومشاغی برابرینه کوتاره‌لر . تکبیر تمام اولدیغی ایله قول باغلاب، جهریه نمازلرده بسم اللهنی فاتحه‌دن هم سوره‌دن مقدم قچقروب ایته‌لر . هر ایکی رکعت‌ده اخلاص سوره‌سنی اوقی‌لر رکوع‌ده «سبحان الله» دیب اوچ مرتبه وسجده‌ده «سبحان ربی الاعلی وبحمده اللهم صل علی محمد وآله» دیب ایته‌لر . سجده‌دن تورغانده قوللرنی براز کوتاره‌لر . قراءت‌لری سارت قراءتی قبیلندن ضعیف در . لکن هر آیت‌ده وقف ایده‌لر . اذان ایتوچیلرنی سنت وتر اوقدقلرنی کورمادم (۱) .

۱۹ــده دوشنبه کیچه‌سنده یستودن صونك بن فقیر هم فیض الله ایله زین الله برابر کعبة الله ایچینه کرمك ایله مشرف اولدوق . مکهٔ مکرمه‌ده محمد بن علی بن ابراهیم النازلی، رحمة الله بن خلیل الرحمن الهندی ، محمد بن احمد القونیوی

(۱) کوردکمز شیعه کتابلرنك اذان واقامه‌نڭ سنت ایدوکی بیان ایدلمشدر . فقط اذان واقامه‌لرنڭ ارغنه باشقه‌لق باردور . شوننك ایچون بو خصوصده اوزلری‌نڭ کتابلرینه مراجعت لازم اولور .

ایله

قارشو چقنانلر ایدی . عسکر موسیقی اویناب کردی . بازارنده قافله خلقیغه کراکلی نرسه توب ایدی . بو رابغ شام اهلی‌ننك میقاتی اولغان جحفه (۱) دن غروسنده ایکان . شوننك ایچون مدینه خلقی‌ننك کوبسی بوا یرده محرم اوله‌لر ایکان . بو عمل‌ننك درست لکینه امام اعظم (رحمه‌الله) دن روایة هم بار ایکان . وادی فاطمه اسملو منزلده وقت مزده بیك بولوت هم بیل اولدی . کوك کوکراب یاشن یاشنلدی ، ازراق یغمورده بولدی .

۷ ــ ده چهارشنبه کون (۲۹ تشرین اول) مکهٔ مکرمه‌کا کردوك .

﴿ مکهٔ مکرمه ﴾

لازم وتیش اولغان مناسك وعبادتلرنی سلامت لك ایله قیلدوق .

۱۵ ــ ده احرامدن چقدوق . اما عجم‌لر بزدن صونك عرفاتده‌دغی برکون قالوب اونبرنده احرامدن چقدی‌لر شریف عبد المطلب حضرتلری سیاست ایله یوردی بارغان اورنلرنك تدبیرلر آتلوب ، نظامی عسکر موسیقی اویناب قارشو آلدیلر ایدی . مسجد الحرامغه «باب عتیق» دن کرکانده اون ایکی باسقچ توبان توشلوب کرله‌در ، کعبة الله ، جنوب کارکن یمانی زاویه‌سی ایله توره‌در . هر سینده حج وقتنده اخشامدن مقدم سراج (شم) یاندره‌لر . بیت الله‌ده تون بوینچه یاندرلوب ایرته نمازی صونکنده سوندرله‌در . ایرته نمازنی شافعی ، مالکی ، حنبلی ، حنفی ، اوشبو ترتیب ایله اوقی‌لر . اما حنبلی‌لر بیك آز اوله‌لر . هم مکه‌ده کنه ایرته نمازنی اوزلری اوقی‌لر . اوشنداق مالکی‌لرده بعض نمازلرنی غنه اوزلری اوقوب باشقه‌لرده کوبراك حنفی‌کا ایاره‌لر .

---

(۱) جیم صونکنده حاء ایله در . قدیم اسمی « مهیعه » ایدی .

ابراهيم افندى شيخ عبد الجليل المدنى سيد عبد القادر بن احمد الحنفى الطرابلسى مفتى محمد الروبالى ،

موسى افندى ، مدرسه كيلار امينى شيخ خليل بن ابراهيم افندى ، محمد عماد الدين النوركابى ، وغيرلار . شيخ مظهر حضرتلارى ، جمعه دن صونك قبر شريفكا قارشو توروب بنم ايچون خير دعاء ايلدى .

٢٥ – ده شام كروانى ايله مدينه دن سفر ايدوب آبو رلدوق . ذو الحليفه (١) ديكان اورنده احرام قيلدوق . قافله ده حج اميرى سعيد پاشا ايدى . توقتاروكيدر ايچون هر نماز وقتى ايچون توب آتالار . نظام عسكرى كيچه ده قراول توره در .

٢٨ – ده (٢١ تشرين اول) جديده دن اوزدوق . بونده خرمه باغچه لارى كوب ، مسجد ومناره لارى بار . اوشبو كون بيك قزواولدى . قاب ايچنده بولغان قاتى شمع (شم) اريدى . طستلار . توتا الماز درجه ده قزدى .

٢٩ – ده صفراهم بدردن اوتدوك . صفراده خرمه اق كوب . مسجدلار بار . كوب نرسه كوتورب ساتدى لار . بدرده هم بالق ساتوب بوردى لار . شوننك ايچون دينكزكا ياقن درديب ظن ايتدرك . بدردن اوزغاج اونك طرفده اولغان تاوار بتدى . صول طرفده اولغان لارى هم يراقلاندى . آياق آستى قم غه ايلاندى . بيل ايله دينكز هواسى كيله ايدى . ٣ ذو الحجه ده (٢٥ تشرين اول) رابغ غه يتدرك . خاتونى قزى وجمله اهاليسى قافله كا

---

(١) بو اورنى حضرت علىكا نسبت ايله بئر على ديب هم ايتالار .

فارشو

مكه شريفى عبد المطلب ننك كياوى ايمش . صفى پاشا ايله كورشدوك . پالاس غه اولتورتوب قهوه ايله ضيافت ايتدى . اوشبو مجلس ننك مهابت وسلطنته كونكلم طولدى . اوزمنى ضبط ايده آلماى يغلادم .

مدينه منوره تيكز اورنده تاولرى هم تاشلى دكل . توفراقى قزل راق لكن قاتى دكل . هواسى خوش هم ملايم . آرپا وياسمق كبى نرسه لرنى ساچوب اوسدره لر . مدينه ده بيك فروانلق . رمان ' خرمه لرى بيك اعلا . نان بيك ارزن . ايت اوچسز . قاتق لذتلى ' سوت كوب . ليراء مسابى ايله استانبول ننك برغرشى بونده غرش يارم قيمتنده استعمال ايدولنه در . شام قافله سى ننك آت لرى بخشى ' دوه لرى ايرى . تحت روان وغير اسباب بيك مكمل . مدينه ده اولغان عزمتلو اورن لرنى ومبارك مشهد لرنى يوروب زيارت ايتدوك ودعالر قيلدوق . دوستلر واحباب لر ننك ضيافت لرنده اولدوق . مدينه ننك - اكابرلرى ايله كورشوب صحبت ايتدوك . معارفه پيدا قيلوب استفاده ايلدوك . بوجمله دن حسن فهمى بن عثمان ابو عيد در . (١) ودخى شيخ محمد مظهر (٢) بن احمد سعيد الهندى الحنفى در . دخى شيخ آخوندجان بن عبد الهادى البخارى (٣) در .

---

(١) بو كمسنه بولوب اوتمش شيخ الاسلام دور . ترجمه سى ذكر ايدولدى .

(٢) مشايخ نقشبنديه ده معروف ومشهور ذات ايدى . بنك اوچ يوز برنچى سنه ده وفات ايتمش در .

(٣) بو كمسنه عالم وفاضل برذات اولوب حاضرنده طائفده سلامت ديب بيله مز .

مطهره‌ده ایکی رکعت نماز اوقوب مرقد شریفکه و باشقه اورنلرغه زیارت یتدوم . بر اسطوانة استونده اولتوروب حال جیدوم . باروم ساعت صونکنده اذان اوقلدی . محراب‌غه یاقن اورنده نماز اوقدوم .

۱۷ــ ده ایرته نمازینه باردم . شافعی، مالکی حنفی، لر جماعت اولوب مذکور ترتیب ایله اوقدی‌لر . جمعه ده هر ایکی خطبه‌ده « اما بعد » نی ایتوب خلیفه‌لرنی ایکنچی خطبه‌ده ذکر ایتدی .

۲۰ــ ده عزةالله بن عبد المجید الشردانی دعوتینه اجابت ایتدوک . بیك أعلا پلاو ، اویرا ، ایت ، چای ایله ضیافت ایتدی . استانبول دن چقدقدن صونك بو روش‌ده لذتلی نعمت یدکمز یوق ایدی . اوشبوکون اخشام نمازندن مقدم ، بن فقیر کثیر الوزر والتقصیر آق‌جبه کیوب ، بیلمه‌یاولق بیلاب حجرة السعادةکه کردم . برنچه قندیللارکه سراج ياندردم . رسول اکرم افندمز (صلی الله علیه وسلم) که وحضرت فاطمه‌غه سلام ویروب دعاء قیلوب چقدم . ایکنچی کون ایرته نمازنی شافعی‌لر ایله اوقدوم . مسجد شریفکه خاتونلر هم حاضر اوله‌لر

۲۲ده‌ــ مدینه‌ننك باب الشام اسملو قاپوسندن چقوب حضرت عثمان قبوسینه باردوق . شونده هم شام قافله‌سنی قارشو آلورغه دیب مدینه حاکمی صفی پاشا چقەش ایدی . بخشی پالاس‌لر جابولکان ایدی . مکه مکرمه دن شریف عبد المطلب طرفندن وکیل اولوب شام قافله‌سینه قارشو کیلکان ذات اولتورغان ایدی . بوذات اوزی شریف‌لردن هم

مکه

نمازنی اوقوب آزراق یوقلاب هم تیرلکان ایدم . شونده حاجی اشمحمد اسملو قزاق کیلوب قولمنی آقرن‌غنه هم اوزاقلاب اودی . شونده قولم هم بیك راحت‌لندی . صونکره مدینه اهلندن حاجی شعبان بن عبید اسملو کمسنه برلیمون کیتورب دخی آق یب صوراب آلوب آنی برنچه‌قات ایدوب یدی اورندن تبونلاب رقیه قیلوب اونك قولمه بیلادی . ایبداش لرمز ، بو ذاتنی ینبع‌ده ابراهیم پاشا ایله کرکان ایدی دیدی‌لر ، لکن بنم خاطرمده قالمغان ایمش . بوکمسنه‌ننك بزکاکوب فائده‌سی اولدی . خصوصا دوه‌چی‌لرکه « بونلر یخشی کشی‌لر ، خدمت ایتونکز رنجتمانکز » دیب تاکید ایله تنبیه قیلدی . اوشبوکون هواده ملایم اولدی هم آزراق ینکایکان کبك‌ده اولدم .

۹ ـ ده بئر عباس‌ده بزم اوستومزکه ، مکه‌دن چققان قافله کیلوب توشدی . ینبع ایله مدینه آراسی بیك تیکیز تیمر بولیاکه تراموی اشلاتورکه بیك ممکن هم اونکغای . چیت‌ده بولغان عرب قریه‌لرنده ایرته نمازینه ایتکان اذان لری شاولاب ایشتواوب توره‌در .

۱۱ ـ ده مدینهٔ منوره‌که یتوب قربان علی (۱) حاجی تکیه‌سینه توشدوك . بنی مسدیه ، دیکان نرسه‌که اولتورتب دورت کشی کوتاروب آلوب کردیلر .

مدینهٔ منوره

۱۳ ـ ده دوشنبه کون اویله نمازندن مقدم حرم شریف‌که باردم . روضهٔ

---

(۱) قزان‌ننك معروف سوداکرلرندن قربان علی بن مرتضی بن اسماعیل بن یوسف ابن برنای‌در . علم ایله مالنی جمع ایلمشدر . کرچه داچه بناء ایلدی ایسه‌ده مدینه‌ده الوغ تکیه صدقه ایلمشدر ۱۲۶۹ ده حج ایدوب ۱۲۷۵ ده وفات وقزان‌ده مدفون‌در .

يازغان تاش‌لردن تابا آلمغاج بر قبرنی اوشبو اولسه کرك دیب قرآن اوقوب باغشلادوق . الله‌تعالی قبول وروحنی شاد ایلسون .

٣ــ ده جمعه اوقدوق . خطیب ، الحمدنی برکنه مرتبه ایتوب ، مفرد ایله «اشهد» دیدی . خلیفه‌لر (رضی‌الله‌عنهم) نی ایکنچی‌خطبه‌ده ذکر ایتدی ؛ یخشی ومرغوب دوش‌ده اوقدی .

٤ــ ده راشد ، عید (٢) اسملو کمسنه‌لرنی دوه‌لری ایله یاللاب مدینه‌گا کیتدوك . دوه بر ساعت‌ده بنك اوچ یوز آلتمش آدم آتلی ایمش . اما شام کروانی‌ایله واردقمزده شام دوه‌لری‌ننك بنك اوچ یوز آدم آتلادقلرنی سانادوم . صحراده الوغ وسانچکلی آغاج کوروب بر عرب‌دن اسمنی‌صورادم «شیر» دیدی ، ینه قادتاروب «طلح» دیدی . بئرسعید دیگان منزل‌گا یتکاچ خسته‌لندم .

٧ــ ده جدیده‌ده اولدوق . بوننده بیوك تاو باشندن چیشمه اولوب آغوب چقغان صوبار ایکان . صوی اسسی هم قوتلی بولوب آغه‌دور . بعض‌لر بونی زبیده (١) یورتکان صودیب روایت ایتدی‌لر . ایرته

سکسان‌بر سنه‌سنده حج‌دن قایتوننده وفات‌در . ملت‌نی اونتمغان بای‌لرنی ملت هم اونتماز . شوننك ایچون فاضل مرجانی هم ازلمشدر . بزدن صونکغی‌لرده اونتماسونلر ایچون بزهم بواورنده یازوب قالدره‌مز

(١) عجب مبارك اسم‌لر دوغری کلمش ایمش .

(٢) بوزبیده ، هارون‌الرشید خلیفه‌ننك خاتونی‌در . کوزال‌لکده ، فصاحت وبلاغت‌ده نظیرسز اولمشدر . اوشنداق تقوی ودیانت بابنده برنچی درجه‌ده اولوب سخاوتی هم فوق العاده‌در . عین زبیده اسملو یلغه‌نی حجازده یورتدکی‌کبی تبریز شهرنی هم بناء‌ایلمشدر ١١٦ هجری ده‌وفاتدر

نمازنی

دورت آلتون یاکه آلتون لنغان کموش تزکان اوله در . دخی الوغسی بز ننك
اون ایکی مثقاللی اولچاوکبك ، قالغان لری بری برندن کچکنه مثقاللقلر روشنده
نرسه لرنی مانکلای لرندن بورن اوچلرینه قدر تزوب توشرکان اوله در .
موین لرنده اوچ یاکه دورت قات مرجان یاکه صدف کبی نرسه تزوب سالغانلر
باش لرینه بورکانکان لر . بو بورکانچك کو براك قاره توس ده اولوب ایاقلرینه
قدر قاپلاغان در . اما خادمه لری ننك یوزلری وکوکراکلری آچق وآیاق لری
یالانغاچ اوله در . بعض لری کیچه ده شعر هم ایته لر . ینبع ده خانون لر حتی
کچکنه لری ده اورام غه چقمای لر ، کشی کاکورنمای لر ، تاوش لرنی ایشتدرمای لر
ایکان . ینبع اسکله سنده چیت کاتاش تزکان . اورام ده دینکز بو بلاب نچه اورنده
بغدای اویوب قویغان لر . کچه آشاماسون دیب (۱) عرب لر بغدای ننك
اوستو ینه منوب اولتورغان لر . ینبع ده چبن بیك کوب لکن اچی تشلمای لر .
بولمه مزکا بر کمسنه کروب چای ایچوب چقدی بونی کورب مصردن
کلکان چرکس شاکردلری عجب ایدوب ماشاءالله اول ابراهیم پاشادیدی لر .
ینبع ده آی کورب هم تکمیل ایله ذوالقعده باشی چهارشنبه کون اولدی .
۲ ــ ذوالقعده ده فیض الله هم زین الله لر ایله قبرلك کا باروب حاجی حسین
(۲) بن یوسف قبرنی ازلب ، تاش لرنی تفتیش ایدوب یوردك . لکن

---

(۱) آنده هم کچه خوفی بار ایکان

(۲) بو کمسنه قزان ننك ایسکی فکرلی یعنی ولوسپیی طائفه سینه باشقه
اولان لردن در . ینکل ترکلیك ایدوب وکوب مالنی اوزی تابوب وارثلرنی
بای قالدرمش وخیرات ایچون کوب مال صرف ایلمشدر . بنك ایکیوز ـ

صونگغیبسی ننگ نومیری (۱۷۷) ایدی . روسیه آربه‌لرنده سکسان‌سکز کشی‌لک اورن‌اولوب) پیج اولمغان‌سببلی بونداغی آربه‌لرده‌توقسان‌آلتی کشی‌لک‌ایدی . اسکندریه، مصر، سویس‌تیمریولی اوستونده زاودلر کورلوب قاله‌در . مصردن کیتگان کونده سویس‌کا باروب یتدوک

سویس

سویس‌ده حاجی علی‌الخنواقندی‌غه توشدوک . بونده‌اوچ‌کیچ قوندوق ، ایلول‌رومی (سنتبر) ننگ ۱۸ نده‌اخشام‌صونگنده‌دینگزکاکروب‌غسل‌قویندوق بوشهرده قبط هم نصاری‌لرغه خاص اوچ بیعه واهل اسلام‌غه خاص بیش جامع‌واردر . برجامع‌غه کروب نماز اوقدوق . ایکی‌باسقچ ایله‌منه‌در . بر باسقچی اون‌اوچ قدم ایدی . اخشام‌ده شمع (شم) یاقمای‌لر ایکان .

۲۶ ــ ده پاپور ایله‌یوللاندوق . ایکنچی‌کون‌ایرته نمازی‌صونگنده‌اوستومده یالغوزبرقات‌جیلان‌اولدیغی‌حالده ، صوباسقچینه‌باسوب‌یوسف‌سوره‌سنی اوقوب باردم .

ینبع

۲۹ ــ ده‌ایرته ینبع بلده‌سینه چقوب‌احمد بن‌علی اسملوکمسنه‌کا توشدوک . ایکی‌مجیدیه‌کا برقوی‌ساتوب آلدوق . عرب‌لر : بلح‌دیب‌خرمه ، خبزدیب نان ، فطیر دیب‌بلن ، سمک‌دیب قزل ، زنگار ، یاشل ، چوار توسلی بالق‌لر کیتروب‌ساتوب‌یوردی‌لر . عرب‌خاتونلری ، کوزلرنی ، بورن‌لرنی‌آچق قالدروب‌اوچ پوچماقلی قارانرسه‌نی‌یوزلرینه‌قاپلاب یوری‌لر . اول‌نرسه‌کا

دورت

براورنده در . بزلر اینك الوغ ننك ایچینه کردوك • توبی کینک اوچی
تار اولوب یراقدن آرش کیبانکرو شنده کورنه در . اما اوزی بیك بلند در .
طشندن اوچ طرفدن جیاو باروب باسقچ یصالغان . اونبش آرشین
مقداری ، مذکور باسقچ اردن بنکان صونك ایچینه کرله در • کرکان
صونك کاها توبان توشوب کاها دوغری باروب بر بولمه گا کرله در •
شول بولمه دن طشغه چقارغه ایکی یول بار • بوننك ایچنده یوروب
کورکان صونك خرمه ایله تاری ایکه کی صاتوب آلوب آشادم
نیل بوینه اوتوروب صو ایچدم . شهر ایله اهرام آراسی ساعت یارومق
مسافه در : اون اوچ چاقروم اولور دلیللار بنه ایکی تنکه هدیه ویردوك •
یولنی دانبه ممالنده کوتاروب اشلکان . هر اوچ آرشین ده آغاج
اولتورتقان لر • یول بوینده عسکریه یورتلری اولوب
باغچه لری کوزال در . اما طه لری تاش قیمه و تیمر راشتکه اولوب قابقه لری
تیمر در • آرادن اوچ قانال در بنانك برقاتنده اوچ بوز تر زه سانادم •
بو سفرمزده سعودبك الفلکی گا قوناق اولدوق • عالم ومتواضع مجلسی
خوش کوسنه تابدم . دوامزده ابراهیم باشاننك تمثالنی کوردك . بیوك
تاش اوستینه چوین آت غه بندروب چویندن قویوب قویغان . بر قولنی
سوزوب بر نرسه کورکزوب توره در • سقالی آغارغان باشینه فس کیکان
۲۳ ــ ده تیمر یول ایله سویس کا سفر ایتدوك . زقازیق اسماو اورنده آربه نی
آلماشدردی لر . مصردن چقغان آربه مزننك نومیری (۱۰۴۷) اولوب

یازولر وشعرلر کوب در . بعضی لرنی نقل ایدوب آلدوق (١) کوشکنی هم کروب کوردك . آننده حمامی وکنیفی هم باغچه سی بار . بو لمه لری بیك کوب ، هر قایوسنده اعلا پالاس لر جایولغان ، اوستال ، کنافی کروات ، کوزکی لری هیچ بیان ایدرلك دکل ، اوزی ننك (محمدعلی باشا) تربه سینه کروب دعاء قیلدوق . جامع طرفندن قاراغانده مصر شهری تمام کوره در . نیل یلغه سی هم جایلوب یاته در . آندن جامع الساریه کا وآندن سادات بکریه کا واروب زیارت ایتدوك . اوشنداق شیخ شاطبی حضرتی ننك قبرنده دعاء ایتدوك . بونلردن باشقه معروف عالم لر ومشهور ایرلر ننك خصوصـ شریف لر وسیدزاده لرننك قبرلرینه باروب زیارت قیلدق . وتورلی جامع لرنی یوروب کوردك .

٢٢ ـ ده دوشنبه کون مصردن محمل (٢) شریفنی ، توب آتوب ، موسیقی اویناب ، بارابانلر صوغـوب ، غایت ده سلطنت ایله اوزاتدی لـر . اون یدی ده ایله یباردی لر . بو دنن صونك بر فرانسز آلتونینه فایتون یاللاب اهرام (٣) غه کیتدوك . اهرام لر کوب اولسه ده اوچ عدد الوغ لری

---

(١) نقل ایلمش شعری اوشبودر : وهل یا صاح یعرب عن علی : مؤثرة دون البناء المشید ؛ فدع قصر عمان او اهرام هرمس : وایوان کسری ان اردت تهتدی ؛ ودع ارما ذات العماد ونحوها : وعرشا لبلقیس کصرح ممرد ؛ ودع اموالشام وانزل بمصرنا : وبادر الی هذا بایماء مرشد ؛

(٢) مصر القاهره خصوصنده یازلغان کتاب لردن بو محمل ننك کعبهٔ شریفه کسوه سنی یوکلاکان محمل ایدوکی فهملنه در . مذکور کسوه نی اوزاتقان کونده مصر اهلی ایچون بیرام اوله ایمش .

(٣) فرعون لرننك مزارلرینه بناء ایدلمش اولوغ بنالردر . مصرده اوتوز توقز عدد اهرام وارلغی روایة ایدولنه در .

ایکی رکعت نه‌ل اوقدی‌لر. فرض نمازنی تمام ایتکاچ هرکم اوزی سنت نی اوقوب چقوب کتدی‌لر. امام ایله برکالب دعاء ایتمك اولمادی. بوشهرده ' دنیال (علیه السلام) لقمان الحکیم ' اسکندر ' سعد بن ابی وقاص مشهدلری ' دیب عوام الناس ' زیارت ایدوب یوری لر.

۱۹ــ ده ابو العباس جامعنده جمعه اوقدوق. خطیب ننك قولنده خنجال ایدی حمدنی برکنه مرتبه ایتوب شهادتنی‌هم « اشهد » دیو مفرد صیغه ایله ذکر ایتدی. خطبه‌سی کوزال ایدی. فرضدن سلام ویروپ بر طرفغه توروب کیتدی.

۲۰ــ ده تیمر یول ایله مصرغه کیتدوك. اورنمز ایکنچی درجه‌ده ایدی. نیل یلغه سندن تیمر کوپردن اوتدوك. هر منزلکا یتکانده ' فلان منزلکا یته‌مز ' دیب چقروب باره‌لر ایدی. مسقوف ایله آدیس آراسنداغی یولده تلغرام باغانه‌لرینه قویلغان رقم لرنی اوقوب باره‌در ایدوك. اما بو یولده آلای اوقورغه ممکن اولمادی بلکه باغانه‌لری کوزگه چاغلوب غنه قالادر ایدی. قزو وتیز یروندن عجب ایتدوك.

مصر القاهرة

۲۵ــ ده قاهره‌کا یتوب حاجی کمال الدین حجره‌سینه نزول ایتدوك حجره‌سی بیوك ایدی ، قرق‌سکز باسقچ سانادم . مصرده الوغ بنالر بیك کوب . بو جمله‌دن برسی محمدعلی پاشا جامعی‌در . بو جامع کرچه استانبول جامع‌لری کبی زور دکل ایسه‌ده ' مصنع ومکلف وذینتلو لکده بیان ایدرلك دکل . ایچی وطشی تمام مرمر تاشندن یونوب اشلنکان . عقیق (احق) مثالنده قب قزل‌در . قبه‌سی تمام آلتونلنغان دور . دیوارنده عربی ، فارسی

احتياط الظهر نمازنى هم اوقمادى . كرچه ممدنى تكرار ايتمادى ايسه ده «نشهں» ديو توارثكا خلاف قيلدى . ازمير جامع لرى بزم مقه برله ابره دن (۳۶۵) ننك سكزدن برسى قدر صولده در . بونده جامع لرننك محراب لرى اوستونده « فلنولينك قبلة ترضيها فول وجهك شطر المسجد الحرام » آيتى وديوارلرنده « ان الصلوة كانت للمؤمنين (۱) كتابا موقوتا » آيتى يازلمشدر . اذاندن مقدم مؤذن لر صلوات ايته لر ، اما استانبولده فرض دن مقدم اوچ مرتبه اخلاص سوره سى اوقى لر . جمعه دن صونك قراءت اوقلمايدور .

۱۲ ـ قوياش بايوغان وقت ده ازميردن كيتدوك . آندن ساقزغه ، آندان يونان ننك معمور شهرلرندن برسى اولغان « شيره » شهرينه باردوق . استانبول اهالى سندن بريكت ايله بيلش اولوب تمام عربى سوزلب باردق . حسن خلق وعقل هم فراست صاحبى ايدى . مصرده دولت خدمتى ايده من ديدى .

اسكندريه (۲)

۱۷ ـ ده پاپوردن توشوب قولدش باى بن كمال الدين البخارى كه نزول ايتدوك . بونده جامع لر بيك كوب اولوب مشهورى ، امام بوصيرى جامعسيدر هم ده بو جامع بيك كوزال وسلطنتلى در . قبه سى آلتى چوبن باغانا اوستونده در يخشى پالاس لر توشلكان در . اورام لرى ننك كوبى طوغرى هم تيكز اولوب تاش تزلكان در . فايتون وآربه لر بيك يخشى . خلق بيك كوب اولوب عربى سوزلاشه لر . اخشام اوقورايچون كردكمز مسجد ده شافعى لر ، فرض دن مقدم

---

(۱) آية كريمه ايسه « على المؤمنين در » بواورنده بلكه سهو قلم ايله للمؤمنين يازلمش اولسه كرك .

(۲) بو شهرنى اسكندر رومى بناء ايله شدر . بو كمسه نى اسكندر يونانى ديب هم ايته لر . هجره دن توقز يوز او توز بش سنه مقدم كلمش بر مشهور پادشاه در .

ايكم ،

کورشدروب ' برداش مز دیدی . بو قارت قورقورچیکوب حضور قیلوب اوتورمقده ایدی . حال صوراشقان صونك بو کمسنه ' ضیاء مضافاتنده قشمان امامی شراف الدین بن فخرالدین ننك عمی شمس الدین حاجی ایدوکی معلوم اولدی . ۱۲۴۸ نچی یلده بخاراغه باروب بیش یل توردیغی بعدنده بوشیرکا کلمش ایمش . بالالری واحفادلری هم اولمش . دنیاسی ایرکن واسبابی مکمل ایدوکنی بیان ایتدی . دخی برای قصبه سی یاننده توغای اولی ننك حسن یار بن شاه مردان نام کمسنه کیلوب کورشدی . دلیل اولغان سیف الله افندی کوستنجه دن هجرت ایتدوکنی سوزلدی ' اوّلده بای ایدوم حالا فقیر اولدم دیدی . جمعه اوقورایچون مسجد کا کردوك . تحیة المسجد نمازنی اداء ایدوب بر جزء قرآن شریفی اوقدم . اوقدقم قرآن شریفی غایتده خوش خط ایله یازلمش ایدی . بیت آخرلرنده آیت تمام ایدولکان' لکن رسمی سقیم اولوب وقفلر هم رعایه ایدولمکان کورلدی . هود (علیه السلام) سوره سنده « ولا تمسوها بسوء » آیتده « لا » کلمه سی قالغان هم ' ولا ترکنوا الی الذین ظلموا » آیة کریمه سنده « الذین » اورنینه « الله » لفظ شریفی یازلغان ایدی . بو ایکی یانکلشنی توزاندم . بو وقت ده بر کمسنه سندره دن چقروب کهف سوره سنی اوقدی . کرچه وقفلرنی رعایة ایتمای ومدلرده افراط ایتسه ده ' باشقه جهتلری خوش ایدی . مناره اذانی وقتنده اون ساعتلری هم بزم ساعتمز آلتی غه اون دقیقه یتمکان ایدی ' امامنبر اذانی وقتنده آلتی نی صوقدی . منبری اون دورت باسقچ ایدی . خطیب ' قولینه بر نرسه ده توتمای منبرننك یارومده باسوب ایکی قولنی ایکی یاق توتقاغه قویوب اوقدی , فرض ده انا اعطینا ایله قل هو الله سوره لرنی قوشدی .

قولنی آلوب اوپدم واثرلندیکم ءالده وداع ایلدوم. بو وقتلرده معارف ناظری منیف پاشا معزول اولدی. شوال — ۷ — ده صدر اعظم قدری پاشا معزول اولوب، سعید پاشا نصب اولندی.

۱۵ — ده پاپور ایله استانبولدن آیورلوب اسکندریه‌گا یوللاندوق. کلیبولی چناق قلعه، مدللی' نی اوتوب ازمیرده توقتادوق. توقتاغان وقتده ایرته نمازی اوقوب تمام ایتمش ایدوك. شوشی وقتده بر ایرانلی کیلوب بندن قبله‌ صورادی. بن کورکزکان طرفغه قاراب ایکی رکعت نماز اوقدی. قیامده قوللرنی کندوك آستوینه قویب ایکنچی رکعتده الحمدگا قل هو الله سوره‌سنی قوشدی ورکوعدن مقدم قنوت اوقدی. اولتوردقنده ابن مسعود (رضی الله عنه) تشهدی کبی اوقوب لکن اوّلکی تشهدده «وحده» کلمه‌سنی آرتدردی.

ازمیر

۱۶ — ده ازمیر شهرینه چقوب تفرج ایتدوك. اسکله‌سی کوزال اولوب یونغان تاش جایولکان. خوش مسافرخانه‌لری وار. تیمر یولنده بر آت ایله ترامو ی یوریدر. آذرن باشقه تیمر یوللری وکوزال دکانلری وار. ایشاك، قاچر، دوه‌لر ایله اوشنداق آربه وحماللر ایله هر تورلی نرسه‌لر تاشوب یاته‌لر. فایتون وکاریته‌لرده بار دیدی‌لر. بیك زینتلی سوداخانه‌لر وماشینالو فابریك وزاودلز وار. یوزم، انجیر، پورتقال، وغیر نرسه‌لری بیك اعلا هم فروانلق. ایت‌نك یخشی‌سی کوب. مسجدلر وکنیسه‌لری کوب وکوزال ایمش. کینك اورام‌لری بار، کوبراکی تار ایکان، لکن جمله‌سینه تاش توشلکان قایق ایله باروب کیلمك بیك ارزن. یولده اجی‌نك سیف الله بن علی نام کمسنه اوچراب دلیل اولوب سیاحت ایتدردی. هم بر موی سفید کمسنه ایله

کورشدروب

ترکیچه بیلسه‌ده بنم ایله عربی سوزلشدی. فائده‌لو سوزلر ولذتلی
صحبتلر اولدی. غایت‌ده عالم وفاضل ایمش. تاریخ، جغرافیه، هیئت‌دن
خبردار ایدوکنی بیلوب عجبلندوم. ناظورة الحق نامنده تألیفمز وار
ایدوکنی ایشتدوکنی ومطالعه ایتمیه ارزوسی کامل ایدوکنی بیان ایتدی.
ولایتمزده کون، تون، قویاش چقمق وباتمقلری حقنده صوراشدی
مملکتمزننك شاکردلری وعالملری وعموما مسلمانلری حقنده کوب
استفسار ایتدی. اوروپامعارفیننك خلقمز آراسنده اولوب اولمادیغی حقنده
سؤال ایتدی. بن‌هم آرامزده اولغان علمننك مرتبه‌سی، درس روشلری
حقنده معلومات ویردم. هنر علماری‌ننك آز ایدوکنی، اولغانلری هم
قاعده‌سز وتطبیق‌سز ایدوکنی حسرتلنوب بیان قیلدوم. هیئت جدیده
بر «مقاله‌م» وارلغندن خبر ویردم. بونکا قارشو بیله ایسه، مذکور مقاله‌نکز
ایله ناظورة الحق‌نی قزانغه قایتقاچ بنکا یبارنکز دیدی. دفی سز اوزنکز ترکی
وقومنکز هم ترکی ایمدی، آنلر ایچون یازلان کتابلرننك ترکی تلنده
اولمغی لازم ایدی؛ اماسز اثرلرنکزنی نیچون عرب تلنده یازاسز؟ «دیدی.
جوابنده» عرب لسانننی علمامز وشاکردلرمز بیله‌لر، اوشندای باشقه
ولایتلرکاکیتسه‌ده بلکه قاراوچیلر اولور ظن ایدوب عربی یازامز
«دیدم. بوسوزمزنی موافق کوروب بلی عرب لغتی مشترك لساندر،
دیدی. چقارغه رخصت صورادغمده بوصحبتدن طویمادم قایتونکزده تکرار
کیلونکز دیدی. عصر سعادتدن یراق قالمش ایسه‌کده الحمدلله شریف
ذریتنی کوروب مجلسدش اولمق بزه هم نصیب اولدی؛ دیه خطاب ایتدکمده
غایتده ممنون اولدی. چقدقمده اورننددن طوروب برقدر مسافه اوزاتدی.

کشی ، کورکام یوزلی ، قامتی مستقیم غایتده ظریف وادیب کمسنه ایمش . عربی ، ترکی ، فارسی ، لسانلری ایله فصیح سوزلرکا ماهر ایدوکی معلوم اولدی . بوننك حضورنده درویش بن ابراهیم الکردی البغدادی ایله هم کورشوب بیلشدوك . اوشنداق سید فضل بن علوی بن محمد بن سهل الحضرمی الشافعی منزلنه واردم . اوزی سلطان حضورنده اولدیغندن بزنی اوغلی قبول ایلدی . بو مجلس ده سید عبد القادر الجزائری ننك اوغلی هم بار ایدی . بر قدر وقت اوتکاچ سید فضل حضرتلری قایتوب کیلدی . خوش مجلس وصحبت هم اولدی . شوکانی (١) ، بهوپالی (٢) لردن سوز اولدیغنده سید فضل حضرتلری وهابی لر دیه تعریف ایتدی لکن اوغلی ، شوکانی ننك علمی کامل ایدوکی ایله اقرار ایتدی . اوشبو زیارت ایتدکمز حرمتلو ذاتلرغه کندی تألیفلرمزدن هدیه لر تقدیم ایتدوك . اوشبو کونلرده هم میرزا صالح افندی ضیافتنه ده باردوق .

٩ ـ ده خارجیه ناظری عاصم پاشا وشریف مکه اولان سید عون بن محمد بن عون (شریف حسین ننك برادری اوله در) ایله ملاقات ایتدوم . شریف جنابلری

---

(١) محمد بن علی بن محمد الشوکانی رحمه الله در . غایتده عالم وفاضل کمسنه اولوب اقران بلکه اسلافلرندن تقدم ایلمشدر . یمن ده قاضی القضاة اولوب تصنیفاتی حساب خارجنده در . فتح القدیر اسمنده دورت جلد تفسیری هم باردر . اتباع لری مجتهد مطلق ایدی دیو بیان ایده لر . ١٢٥٥ سنه سنده وفات ایتمشدر .

(٢) ابو الطیب صدیق بن حسن الحسینی رحمه الله در . بهوپالده نواب اولوب بوننك هم تألیفی کوبدر . دورت جلدده اولغان فتح البیان تفسیری بوننك اثری در . ١٣٥٩ ده وفات ایتمشدر .

ترکیجه

بوندن طش ایمش . اوزفنی ایله اشنا اولمغان کمسنه ایچون بونی تعریف ایلمك ممکن دکلدر . عارف بیك بزلرنی خوش قبول ایدوب ممنونیت اظهار ایتدی . اسملرمزنی صوراب آلدی . کلکان قایقلرمزنی قایتاررغه بیوروب بزنی شاهانه‌لق قایقلر ایله یباردی .

عسکرلر ایسه بزنی تعظیم ایدوب اوزاتوب قالدیلر . اوشبو کون شیخ محمد افندی الادرنه‌وی کا باروب ملاقات ایتدوك . موی سفید کمسنه ایکان . کندی‌نکز تشریف ایتدنکز ، بن اوزم وارەچق ایدوم ، دیدی . بو کمسنه شیخ الاسلام حسن بن عثمان فهمی (١) ننك شاکردی ایمش .

٦ ـ ده شیخ الاسلام احمد اسعد افندی حضورنده اولدوق . خوش صحبت ومجلس اولندی . صونکره عدلیه ناظری جودت پاشا (٢) حضرتلری ایله کرشدوم . تکریم ایله قارشو آلدی . بیشکطاش وبك اوغلی طرفلرینه باروب نقیب الاشراف سید سلمان البغدادی (٣) حضورینه کردم . یاش

---

(١) ابو حیدر حسن بن عثمانی بن حسن رحمه الله‌در . ترکیاننك الوغ علماسندن اولوب ایکی مرتبه شیخ الاسلام اولمشدر . محمد بن علاء الدین ابن عابدین رحمه الله . بو کمسنه‌نی قرة عیون الاخیار نام کتابنده ذکر ایده‌در . فاضل مرجانی حقنده حسن ظنی کامل ایدوکی روایة ایدولنه‌در . بنك ایکیوز توقسان سکز سنه‌سنده ، سکسان یاشنده ایکان ، قتنده مدینه‌ده وفاتدر .

(٢) احمد جودت پاشا بن اسماعیل بن علی بن احمد بن اسماعیل بن احمد‌در . بنك اوچیوز اون ایکی سنه‌سنده ذوالحجه‌ده وفات اولمشدر . زمانمزده مشهور مؤلف علمالرزمره‌سندن معدود برذات ایدی .

(٣) بو کمسنه محمد بیرم بن مصطفی بن محمد ننك شیخی اوله‌در . صفوة الاعتبارننك بشنچی جزئی اونونچی فصلنده اسمی مذکور اولوب آخرنده ١٢٩٩ سنه ١٩ جمادی الاولی تاریخلو بر مکتوبی هم مطبوعدر .

ایدلمش ایمش. امالیاصوفیه‌ده دخی بر خاص خرقهٔ سعادت، علم شریف، باشدق شریف، مصحف عثمانی شریف هم باردر. سلطان محمد الفاتح بن مراد رحمه اللّٰه زیارت ایدوب وجامعنی هم کزوب کوردک صونکره محمدرحیم افندیکا کیلوب افطار قیلدوق.

۱ ـ شوال دوشنبه کون ایرته نمازی صونکنده قایق ایله دولمه بغچه طرفینه چقوب عید شریف اوقدوق. وبو کون اردهٔ ضیاء الدین بن عبد الرفیع المنکاری هم اسحاق دعوت ارینه باردوق ونور عثمانی جامعنی زیارت ایتدوک.

۳ ـ ده وفا جامعنده ایکندی اوقوب کیچه سنده شیخ سلیمان (۱) افندیده قوناق اولوب صحبت ایتدوک وایکنچی کونه قدر خانه سنده قالدوق.

۵ ـ ده سلطان سلیم جامعنده جمعه اوقدوق. سلطان سلیم برنچی، جامعینه باروب، سلطان سلیم وعبد المجید حضرتلرینه زیارت ایتدوک. سید مصطفی بن نجیب نام کمسنه قلمی ایله، سلطان سلیم قبه سینه یازلمش توقز سطر بیت لرنی نقل ایدوب آلدوم. جامع ده نساء سوره سندن برقدر اوقدوم. جمعه صونکنده خطیب حافظ اسماعیل افندی ایله قایق ایله باروب زره‌لی مسعودیه باخره سنی تفرج ایتدوک. بنک باشی عارف بیک افندی، کورکزوب، تفصیل ایله بیان ایلدی. هم اوزمزه قهوه کتوروب ضیافت ایتدی. اوشبو مسعودیه زره‌لیسی آنکلیه ده اشلانوب بشیوز بنک لیرا قیمتنده ایمش. قورال واسباب قیمت لری

---

(۱) شیخ سلیمان بن قدرة اللّٰه القندوزیدر. اصلی قوندز نواحی سندندر. قراکولده طوغمشدر. آناسی طرفندن عبید اللّٰه ایشان قراکولی ویحیی ایشان ترکمانی بر له قرابتی واردر. تخلصی «نقشی» در. حالا استانبولده قرار ایتمکده در. ۱۲۹۸ سنه سنده استانبولده مهران مطبعه سنده طبع ایدلمش «لغت چغتای وترکی عثمانی» نام اثر مفید، اوشبو کمسنه ننک اولیدر.

فضائل الشهور (١)، تاريخ ابى الغازى (٢)، نسخه لرنى برابر آلمش ايدوم.

﴿ استانبول (٣) ﴾

٢٨ — ده سلطان سليمان جامعنده جمعه نمازى اوقدوق. وايكنچى كونده «اياصوفيه» جامعنده اولى نمازى اوقدوق.

٣٥ — ده حضرت ابى ايوب الانصارى جامعنى زيارة ايتدوك. اوست قاتنده اولغان خرقهء سعادتنى زيارة هم ايتدوك. روايتلركا بناء بو خرقه، رسول اكرم صلى الله عليه وسلم طرفندن اويس القرنى (٤) حضرتلرينه هديه

---

(١) بو كتابنى بعض كمسنه لر، عبد الجبار بن عبد الكريم الالمتى كا نسبت ايلمش لر ايسه ده، الله اعلم بلغار علماسى اثارندن اولسه كرك.

(٢) اسمى محمد بن عرب خان اولوب مشهور چنكز نسلندندر. آلتمش ياشنده ايكان وقتنده بنك يتمش دورت سنه سنده وفات اولمشدر. تاتارلر حقنده اولمش اوشبو تاريخى ١٢٨٧ نچى يلده بارون دميزون نام كمسنه طرفندن اجتهاد صرف ايدلوب پيترسبورغده طبع ايدلمشدر. ياوروپا لسانلرينه هم ترجمه ايدلمشدر.

(٣) فاضل مرجانى ننك استانبولغه تشريف لرنى خبر آلوب استانبول غزته لرى بيله يازمش لردر: قزان علماى بنامندن مفتى شهاب الدين آخوند افندى حضرتلرى حجاز مغفرت طرازه كتمك اوزره بو دفعه در عليه يه كله رك بخارا دركاهى پوست نشينى رشادتلو شيخ سليمان افندى رفاقت ودلالتيله ذات حضرت فتوا پناهى ووكلاى فخام حضراتى ايله ملاقات ايدوب مظهر التفات اولمش لردر. افندى مومى اليه شايستهء احترام بر ذات عالى القدر اولوب صرف ونحو ومنطق وكلام ومعانى وفقه وتهذيب اخلاق وتواريخ اسلافه دائر اوتوز قدر عربى شرح وتاليفاتى اولديغى وبونلردن، بعض مقامات عليه يه تبركا نسخه لر تقديم ايلدكارى استخبار اولنمشدر.

(٤) ابن عامردر. ٣٧ نچى هجرى ده شهيد اولمشدر.



١٧ شهر رمضان‌ده هجریه ایله ١٢٩٧ نچی سنه‌ده (١٨٨٠ نچی میلادیه‌ده آب روه‌ی ١١ ده اوله‌در) ایرته نمازی صونکنده مکهء معظمه‌نی قصد ایدوب قزان شهرندن آیورلدوق . پاراخود ایله نیژنی‌کا کیلدوك . آندن تیموریول ایله مسقوف ' کورسکی ' کیف ' بلده‌لرندن کیچوب آدیس‌کا یتدوك بو آراده دقت ایدرلك حادثه‌لر بیلنمادی . قزان ایل آدیس آراسی (٢٣٨٥) چاقروم تخمین ایدولدی .

٢٥ ــ آدیس‌دن استانبولغه یوللاندوق .

٢٧ ــ پنجشنبه کون استانبولغه یتدوك . یانمده اولغان مصحف شریفلردن باشقه ' ناظورة الحق ' حق المعرفة ' فوائد ' منتخب الوفیة ' مختصر الوقایة ' بابریه (١) ' ثبات العاجزین (٢) ' مجمع الاداب (٣) '

---

(١) بابریه‌نك مؤلفی ظهیرالدین بن محمد بن میرزا شیخ در . ٨٨٨ سنه‌سنده طوغوب ' ٨٩٩ ده فرغانه پادشاهی اولمشدر . ٩٣٢ ده هندستانده محاربه ایدوب دهلینی فتح ایلمشدر . (٣٨ سنه پادشاهلق ایتدکدن صونك ٩٣٧ سنه‌سنده قرق توقز یاشنده وفات ایتمشدر . عالم و فاضل کمسنه اولوب مذکور بابریه‌نی کندوسی حقنده یازمشدر .

(٢) بو کتاب ترکی تلنده اولوب مؤلفی ابو محمد الله‌یار بن الله قلی نام کمسنه‌در . خلق‌مز آراسنده مشهور اولوب ' قزانده کوب مرتبه باسلدی . بنك بر یوز اوتوزده وفات‌در .

(٣) مجمع الاداب‌نك مؤلفی سعید قصبه‌سنده امام هبة‌الله بن سید بطال نام کمسنه‌در . ١٢٨٢ سنه‌سنده وفات اولوب سعید مقبره‌سنده مدفوندر .

❁ رحلة المرجانی ❁

فاضل مرجانی نڭ (١٢٩٧) نچی یلده عربستان سفرنده یازنده اولغان
خاطر دفترندن جمع ایدولدی . الوغ عالممزگا بر خدمت اولسون
و دوستلرغه یادکار قالسون نیتی ایله عمر صرف قیلندی . اوز طرفمزدن
هم بعض شیلر درج ایدلنوب · آرقای سزق آستینه یازلدی ·
ملا رضاءالدین بن فخرالدین

" اوفا "

باصمه اولنمشدر قزانده چیرکوف خاتونی نڭ ورثه‌لرینڭ طبعخانه‌سنده
محمدجان و برادری شریفجان الکریمی‌لر نڭ خراجاتی ایلان
١٨٩٨ نچی یلده

باصمه سنه رخصت بیرلدی سانکت پیطربورغده ١٢ نچی دیکابرده
١٨٩٧ نچی یلده

Дозволено цензурою С-Петербургъ. 12 Декабря 1897 года.
Типо-Литографія наслѣдниковъ М. Чирковой въ Казани.



Шиһабетдин Мәрҗанинең 1297 елда
Гарәбстанга сәфәре вакытында
янында булган хәтер дәфтәреннән
җыеп алынган мәгълүматлар.

Олы галимебезгә хезмәт булсын
һәм дусларга ядкәр калсын диеп
вакыт сарыф итеп тырыштык.

Кайбер нәрсәләрнең аңлатмасын
астөшермәләрдә китердек.

Мулла Ризаэтдин бине Фәхретдин

ISBN 978-5-6041838-0-9

